(Башк
К 97

Мостай Кәрим

Таған

С(Башк)
К97

Мостай Кәрим

Таган

ПОВЕСТЬ

Татарстан
Китап
Нәшрияты
•
Казан
1966

С(БАШ.)12
К95

Редакторы *Р. Вәлиева*
Тышлык художнигы *А. Абзгильдин*
Художник *С. Забалуев* рәсемнәре

НБ РБ
0000187395

78914

Баш. республиканская
библиотека
им. Н. К. Крупской
08

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

БӨРКЕТЛЕ

Сезнең Бөркетледә булганыгыз бармы? Юкмыни? Дөньядагы иң матур авылларның берсен күрми ничек түзәсез икән? Кыендыр, әлбәттә. Ә бит Бөркетлене күрү генә түгел, шунда туып, шунда үскән кешеләр бар. Аларга рәхәт, ичмасам, тудыңмы, рәхим ит: Бөркетле.

Шулай да кешеләрне аңламассың. Бөркетлеләр үз ихтыярлары белән кайдагыдыр ерак шәһәрләргә, күз күрмәс, колак ишетмәс илләргә барып йөреп кайталар. Күргәннәрен кызык итеп сөйлиләр. (Мин сугышны әйтмим. Анда берәү дә кызык күрим дип бармаган.)

Йорттан чыга алмаганнары лимон-әфлисуннар үскән ерак җирләр, шаулы диңгезләр, кыш булмый торган илләр, төн булмый торган яклар турында хыялланалар. «Их, шуларны барып күрсәң иде!» диләр. Ә менә: «Их, Бөркетлене күрсәң иде!» — дип уфтанган кешене, нигәдер, очратырга туры килмәде. Кешеләрнең шундый кызыксынмаучан булуына аптырарсың. Кызганыч, әлбәттә.

Бөркетледә, әйткәнемчә, дөнья күргән кешеләр байтак. Күрмәгәннәре дә чи надан түгел. Акны карадан

аералар. Әнә сарык көтүчесе Шәрифулла агайны гына тыңлап карагыз. Иллегә җитеп, читкә аяк атлаганы юк, ә үзе җир шарын биш бармагы кебек белә. «Кызыл буяуны Кызыл диңгез суыннан, кара буяуны Кара диңгез суыннан, ак буяуны Ак диңгез суыннан ясыйлар, янә Сары диңгез, Яшел диңгез, Зәңгәр диңгез бар... — ди ул.— Җылы якта шундый тигез далалар бар, кояш чыкканда йомырка тәгәрәтеп җибәрсәң, кояш батканчы туктамый барачак»,— ди.

Ә Бөркетле карагач, каен, нарат урманнары белән капланган таулар арасында—Урал итәгендә утыра. Аның ике ягында ике зур күл. Берсен Калканкүл, икенчесен Кылычкүл дип атап йөртәләр. Калканы ераграк, Кылычы авыл янында гына. Тау битләвендә үлән яшәрүгә Калканның суы җылынып та өлгерә, ә Кылычның суы җәй уртасында да боз кебек салкын була, керсәң тәнне куырып ала.

Дөньяда һичнәрсә үз-үзеннән генә яралмый. Әлеге күлләрнең барлыкка килүе турында да шундый әңгәмә йөри. Имеш, борын-борын заманда, Уралны илбасарлардан саклаганда, пәһлеванга ук тигән. Ул гөрселдәп җиргә ауган. Уң кулындагы кылычы бер якка, сул кулындагы калканы икенче якка барып төшкән. Калкан төшкән җирдә җылы күл, кылыч төшкән җирдә салкын күл калыккан. «Ни өчен шулай ике төрле су чыккан?» — дип сорасагыз, баягы Шәрифулла агай болай дип җавап бирер: «Чөнки кылыч җан кыя торган яман корал, ә калкан җан саклый торган яхшы нәрсә», — дияр.

Бөркетленең күрке күлләр генә түгел. Аның тирәсендә «кемузардан» ярышып күккә үрләгән таулар, тау араларындагы яшел үзәннәр, кыялардан ургылып чыккан чишмәләр, таштан ташка сикереп уйнаган кыр кәҗәләре, язгы шарлавыклардан көзге кырауларга кадәр тынмый сайраган кошлар ямь өстенә ямь өсти. Язгы күкрәүләр вакытында монда таулар гөрләп тора. Әйтерсең, алар үзләре күкне күкрәтәләр. Урманнарда беләк юанлыгы көпшәләр үсә, аланнарда тургай башы зурлыгы җиләкләр тәгәрәп пешә. Кеше аягы басмаган түбәләрдә бөркетләр бала чыгара. Алар еш кына чаң-чаң итеп авыл өстеннән очып үтәләр. Әнә шул бөркетләр инде моннан бик күп еллар элек авылга исем биргәннәр: Бөркетле.

КҮКРӘКТАУДАГЫ ӘҢГӘМӘ

Кылычкүл янындагы биек түбәне Күкрәктау дип йөртәләр. Аның төньяк битләвен куе карагай урманы каплаган, ә көньяк битләве тап-такыр чирәмлек. Бер карасаң, ул яртылаш чәче алынган малай башына охшап куя. Бу якта ул гел шулай: агачлар тауларның төньяк итәкләренә сыенып үсәләр. Әйтерсең, алар тауларны салкын җилләрдән ышыклар өчен шулай итәләр.

Күкрәктау башына менеп карасаң, күк чите әллә кайда еракка күчеп китә. Түбәндә Җаек буена утырган Тирмә авылының йортлары умарталыктагы умарталар чаклы гына күренә. Ә Урал итәгендә көтүчеләр яккан учакның төтене Шәрифулла агай трубкасыннан чыккан төтен чаклы гына. Тик әллә кайда яткан Кирәмәт кенә аяз көннәрдә караган саен якынайган кебек күренә. Дулкын-дулкын булып күгәреп яткан бүтән түбәләр арасында аның гына башы кояшта ялтырап агарып тора. Җәйге чилләгә кадәр анда кар ята.

Кирәмәт башына менү турында күп малайлар хыяллана. Ләкин анда менү өчен кара урманнар, текә кыялар, тирән чокырлар аша уралып-уралып киткән тар, хәтәр сукмак белән бер көн, бер төн барырга кирәк. Ирмен дигән кеше Кирәмәткә менми калмас, әлбәттә...

Ә хәзергә Күкрәктауның көньяк битләвендә Шәрифулла агайның сарыклары керт-керт үлән ашап йөри. Тау башында эреле-ваклы биш кеше утыра. Сары мыеклы, ач яңаклысы Шәрифулла агай үзе инде. Ә калган дүртесе турында сезнең хәтта ишеткәнегез дә юктыр. Гаҗәп тә түгел. Аларның әлегә һични белән дан казанганнары юк. Өчесе кичә генә төрле-төрле билгеләр белән бишенче классны тәмамлап чыкты. Тәртип ягы да ал да гөл генә булмады. Шулай да койрык-фәлән иярмәде.

Сумала төсле кара куе чәчле, кылыч борынлы, чандыр малай Габдулла исемле. Аның чәченә кулыңны тидерсәң, бармакларың чатнап ябышыр кебек. Ямьшек борынлы, табак битле, юаны — Вәзир. Суыкта да, эсседә дә аның ике бит алмасы гел кызарып янып тора. Вәзирнең күзләрен челт-челт йома торган гадәте бар. Бервакыт яңа килгән укытучы апа, үчекләшә дип уйлап, шушы холкы өчен аны класстан да куып чыгарды. Үзе шун-

дый булса да рогаткадан бик төз ата ул. Өченчесе — Бөркетледә бердәнбер җирән чәчле, сипкелле малай — Айдар. Аның «Кыр кәҗәсе» дигән кушаматы да бар. Шәп йөгергән өчен шулай дип йөртәләр. Дүртенчесе чак кына читтәрәк утыра. Аның әле җидесе дә тулмаган. Тычкан койрыгы кебек кенә толымына матур кызыл тасма кушып үргән. Исеме дә матур аның — Гөлнур. Тик алгы тешләре генә юк. Теш булмагач, авызында һич кенә дә сүз тормый.

Шәрифулла агай бик серле тавыш белән нәрсә турындадыр әңгәмә сөйли. Калган дүртесе тын да алмый тыңлап утыра. Баер якка тәгәрәгән кояшның саргылт нурлары Шәрифулла агайның ысланган мыек очларына төшеп җемелдиләр. Җемелдиләр дә аның аскы ирененә сикереп төшәләр. Шуңа күрә агайның авызыннан чыккан һәр сүзе нинди бер яңа серне ача кебек.

Нәрсә сөйли икән ул? Әйдәгез, колак салып карыйк әле.

— ...Кирәмәт башына менү — бөркет очар биеклеккә күтәрелү дигән сүз ул. Төннәрен аның өстендә, — ди Шәрифулла агай, — учак тирәсендә әйләнгән күбәләкләр төсле, йолдызлар сикерешеп уйный. Алар түбән үк төшәләр — үрел дә тот үзләрен. Кайбер үтә шуклары, ялгыш кыяга сугылып, челпәрәмә дә киләләр. Әнә шуны инде йолдыз атылу диләр.

Әмма Кирәмәтнең зур хәсрәте бар. Аның башындагы кечкенә генә күлдә әүвәл заман алтын-көмеш балыклар мыжгып торган. Бәлки, йолдызлар шулар белән шаярыр өчен тау түбәсенә төшкәннәрдер дә. Балыкларның күптән инде заты корыган, ә йолдызлар иске гадәтләрен һаман да ташламаганнар. Балыкларны бер яман кеше һәлак иткән. Ул күлгә бер генә чуртан җибәргән. Шул чуртан-азмы-күпме гомер үтүгә алтын-көмеш балыкларны йотып бетергән. Тау моңа кайгырган. Шул кайгыдан түбәсендәге күле кибә башлаган. Ул кибеп бетсә, Кирәмәт дөм-сукыр булып калачак. Кояш яктысын да, болытлар акканын да, йолдызлар җемелдәвен дә күрмәячәк. Теге комсыз чуртан да дөмегүен дөмеккән, тик күлдәге җан ияләрен бетереп дөмеккән.

Әгәр батыр егетләр табылып, безнең Кылычтагы төсле алтын-көмеш балыкларны шунда илтеп җибәрмәсәләр, ул күл кибәчәк. Кирәмәт хәсрәтеннән ишелеп төшәчәк. Көннәрдән беркөнне әнә теге ак нур чәчеп торган биек

тау урынында бушлык торып калса, бик күңелсез булачак. Шулай түгелмени, егетләр?

«Егетләр» эндәшмәде.

БАШЛЫК САЙЛАУ

Кояш ерактагы урманга барып төртелгәндә, Шәрифулла агай сарыкларын фермага табан куып китте. Малайлар да кайтыр якка уңайлады. Башлап Вәзир эндәште:

— Кирәмәтнең хәле мөшкел икән...

— Бер чуртан аркасында... — дип кушылды Айдар.

— Чуртан түгел, бер яман кеше аркасында, — дип төзәтте Габдулла. — Кирәмәтне бу хәлдә калдырырга ярамый.

— Күп итеп уылдык җыйыйк та, — дип киңәш бирде Вәзир,— илтеп салыйк. Балык ул уылдыктан ярала ич.

Айдар аны кырт кисте:

— Уылдык түгел, тере балык җибәрергә кирәк.

— Кызыл уылдык магазинда да бар, — дип хәбәр итте Гөлнур.

Малайлар бер-берсенә карашып алдылар. Шундый зур эш турында киңәш барганда бу «ике колакның» артык булуы һәркемгә ачык иде. Карышырга урын калдырмаслык итеп, Айдар сеңелесенә боерык бирде:

— Ычкын моннан!

Ләкин Гөлнур карышты:

— Ычкынмыйм.

— Шыл диләр сиңа!

— Шылмыйм, үзең шыл.

Айдар каты боерыкны кинәт йомшак вәгъдәгә алмаштырды:

— Тыңласаң, тургай баласы тотып бирермен, матурым, хәтта икене дә тотармын.

— Антмы?

— Ант!

Гөлнур шунда ук авыл ягына торып йөгерде. Чуар күлмәге генә җилфердәп калды.

Безнең якта кешеләр житди нәрсә турында аягөсте торып сөйләшмиләр. Акылны утырып җыялар. Малайлар яшел үлән өстенә акыл җыярга утырдылар.

«Кирәмәтне коткарыргамы, юкмы?» дигән сорауны кабатлауның кирәге юк иде. Ул, һичшиксез, коткары-

лырга тиеш. Ә коткару юллары турында фикер төрлечәрәк булды. Айдар колхозның балыкчылар бригадасына барып ярдәм сорарга киңәш итте. Вәзир аны үчекләргә үк тотынды:

— Ярдәм, ярдәм, имеш... Бар, бөтен авылга чыгып кычкыр, ярдәм сора. Мескен! — Ул теш арасыннан черт итеп төкереп куйды.

— Башта ук ант итик, малайлар, — диде Габдулла,— бу — сер. Өндә дә, төштә дә, ассалар да, киссәләр дә серне чишмәстән булсын. Кем дә кем телен тыя алмый, ул сатлык җан дип аталачак. Антмы?

Үзе куш кулын маңгаена куеп ант итте:

— Ант!

Аның артыннан Вәзир белән Айдар кабатлады:

— Ант!

— Ант!

— Уылдыклысын сайлап кына безгә зур бер чиләк балык тотарга кирәк, — диде Габдулла.

Вәзир сикереп үк торды:

— Нигә аны тотып торырга? Мин Кылычтагы балыкчыларның балыгы кайда торганын беләм. Эңгер төшкәч, бер түгел, ике чиләк чәлдереп китерәм мин сезгә. Тик салып торырга мурда гына булсын.

— Батмый. Туры эшне кәкре кул белән эшләмиләр!— Бу сүзләрне Габдулла әйтте. Ләкин алар баягы Шәрифулла агай сүзләре иде.

Вәзир дә тиз генә коелып төшмәде:

— Ничегрәк эре чирттергән була, — диде ул, суза биреп, — әйтерсең, башлык...

— Малайлар! — дип кычкырды Айдар. — Безгә чынлап та бер башлык кирәк. Кем башлык була?

Калган икәү, янәсе төптән уйлаган булып, байтак кына эндәшми торды, чөнки киңәш вакытында һәр сүзгә тиз үк кушылып бару ир кешегә килешми. Шулай да Айдар тәкъдимен игътибарга алмау мөмкин түгел иде.

— Башлыкны сайларга кирәк, — диде сайлау-сайлануларның рәтен яхшы белгән Габдулла.

Шулчак Вәзир үзенең барлы-юклы басынкылыгын бөтенләй югалтып ташлады. Ул, кысык кара күзләрен челтчелт йомып, ялварырга тотынды:

— Малайлар, ә, малайлар, минем бер генә дә башлык булганым юк...— Хәтта аның тавышы да калтыранып китте. — Айдар кыш буе класста староста булды.

Габдулла стена газетасына сайланды, район слётына барды. Бер мин генә...

Вәзирнең уң күзеннән бер бөртек яшь менә-менә тәгәрәп төшәм дигәндә, Габдулланың тау җиле кебек салкын тавышы аны тыеп калды:

— Башлыкны сорап алмыйлар!

Ләкин Вәзир өметеннән тиз генә баш тартмады. Ул үзенчә шундый хәйләкәр юл уйлап тапты:

— Шобага! Кем өскә чыга, шул башлык була.

Инде аңа Айдар каршы төште:

— Шобаганы уенда гына тоталар. Тапкан уен. «Кемузардан» ярышырга да, узган кеше башлык була.

Хәзер Вәзир арка терәбрәк сүз башлады:

— Харап икән. Йөгерекне башлык итәргә, имеш. «Башлык» — ул «аяк» сүзеннән түгел, «баш» сүзеннән алынган — белмәсәң, бел. Иң яхшысы аның төз атуда ярышу. Кем төз ата, шул командир. Әнә, Габдулла әйтсен!

Габдулла, әлбәттә, үз фикерен әйтүдән баш тартмады:

— Иң дөресен әйтимме?

— Әйт.

— Иң дөресе — көрәштә көч сынашу. Кем алышта җиңә, шул башлык.

Габдуллага каршы төшү урынсыз булса да, малайлар озак бәхәсләштеләр. «Кара көч күрсәтеп кенә башлык булу заманнары үткән инде», — дигән өчен Вәзирнең чак-чак кына яңагына эләкмәде. Шулай да, азак килеп, гаделлек җиңде. Өчесенең дә сүзе сүз булды.

Башта малайлар үзләре утырган җирдән авыл читендәге ялгыз карагачка кадәр йөгереп узышырга булдылар. Өчесе дә, балакларын сызганып, Айдар таяк белән сызып билгеләгән сызыкка бастылар.

Вәзир команда бирде:

— Раз, два, пли!

Җәядән ычкынган ук шикелле, Айдар шунда ук атлыгып алга чыкты. Их, йөгерә дә соң! Табаннары җиргә дә тими, тик үкчәләре генә алмаш-тилмәш ялтырап бара. Байтак ара Габдулла да аннан артык калышмады. Вәзир, анасына иярер-иярмәс барган ялкау колын кебек, артта ук торып калды. Аның Айдарга ачуы килде: «Җирән шайтан! — диде ул эченнән. — Ботын таш белән бәреп сындырасыңмыни! Сөрлегеп тә китми бит, ичмасам!»

Айдарның сөрлегергә чамасы юк иде. Ул, Габдулланы дилбегә буе артта калдырып, карагачны килеп кочаклады. Габдулла икенче урынны алды.

Ярты юлга җиткәч, Вәзир лап итеп җиргә утырды. Уң аягын күтәреп, нәрсәдер чокынырга тотынды. Күрәсең, табанына чүп кергәндер. Бераздан ул, аксый-аксый иптәшләрен куып җитте.

— Нигә шулкадәр җан-фәрман чабасың, аякларыңны кызганыр идең чак кына, — дип көлде аңардан Айдар.

— Аягыма чүп керде, — диде Вәзир. — Мине ярышта катнашмаган дип исәплөгез!

Вәзирнең аяк табанына, белгечләрчә җентекләп, тикшерү үткәрделәр. Ләкин анда былтыргы яраларның җөйләреннән башка телгә алырлык һичнәрсә табылмады. Вәзир, бәхәскә керми генә, үзенең җиңелү оятын күтәрергә мәҗбүр булды.

Эшне озакка сузмый, ярышның яңа төре башланды. Башта өчесе дә һәрчак янда йөри торган коралларын — рогаткаларын чалбар кесәләреннән суырып чыгардылар. Бертавыштан ярышның шартлары расланды. Карагачның түбәндә генә серәеп торган коры ботагына Айдарның чигелгән түбәтәен куйдылар. Карагачтан утыз адым үлчәп, таяк кададылар. Шуннан торып атарга тиешләр. Һәрвакыт кесәләрдә йөри торган запастан иң йомры, иң шома өчәр таш алдылар. Өч атуда түбәтәйгә кем күбрәк тидерә, димәк, шул ота. Чиратны алфавит буенча билгеләделәр. Беренче булып Айдар атты. Беренче таш выжлап очып китте, ләкин кайда барып тигәнен берәү дә күрмәде. Икенчесе — шап итеп карагачның үзенә сугылды. Өченчесен Айдар бик озак төзәде. Инде монысы түбәтәйне очырып алып китәргә тиеш иде. Ләкин таш үз юлына китте, түбәтәй кымшанмый тора бирде.

Икенче булып мәйданга Вәзир чыкты. Башта ул бик җитди кыяфәт белән бераз мишеньга карап торды. Ашыкмый гына рогаткасын корды. Менә ул төзи башлады. Нәкъ шул вакытта аның җәлпәк борынына бер черки килеп кунды. Ләкин Вәзирнең аңа исе китмәде. Моны күреп торган Айдарның эче пошты: «Куркак син, черки, — дип тиргәде ул эченнән теге озынборынны. — Борынына кунганчы, күзенә килеп керсәң, ни җирең кимер иде, юньсез... Җитмәсә, минем чигелгән түбәтәйгә ата». Айдар сукранып та бетә алмады, түбәтәй очып та китте.

— Бер коймакны майладык, — диде Вәзир, эре генә. Габдулла йөгереп барып түбәтәйне кире урынына куйды. Икенче атуда түбәтәй, ямьшәеп, тагын да килеп төште. Бу юлы Айдарның башы чатнап китте. Таш, әйтерсең, аның түбәтәенә түгел, маңгаена килеп тиде. Вәзир үзенекен кабатлый бирде:

— Ике коймакны майладык.

Өченче ату бәхәсле булып чыкты. Түбәтәй төшүен төште, ләкин ул ботак селкенүдән генә төште. Таш

бу юлы түбәтәйгә түгел, ботакка тигән иде. Вәзир тагын да тантаналырак итеп янә кычкырган булды:

— Өч коймакны майладык!

— Майламыйрак тор әле... — диде Айдар, эчтән сөенеп, — маең җитмәс!

— Күзең кызамыни? Эчең әрнимени? — Өченче атуның буш булуын Вәзир үзе дә белә иде. Ләкин мактанчык йөгерекне үчеклисе килде. — Менә шулай атарга кирәк, Айдар энем, — дип кәпрәйде ул. — Бу сиңа тыртыр йөгерү түгел.

— Шулкадәр мактанудан ничек телләре талмый, — дип пошынды Габдулла. — Вәзирнең өченче ташы барыбер исәпләнми. Хәрәмләшмә дә!

Вәзир дә артык тартышмады. Чөнки ул Габдулланың уза алмасын яхшы белә иде. Чынлап та, Габдулла, өч атудан бары бер генә тидереп, икенче урынга чыкты.

Ялгыз карагачның күләгәсе Вәзирләрнең бәрәңге бакчасына барып җиткәндә, көрәш мәйданы ачылды. Шобага буенча, башта Вәзир белән Айдар, учларына төкереп, кара-каршы килеп бастылар.

— Алыш бармы, җиңеш бармы? — диде Айдар.

— Алыш та бар, җиңеш тә бар! — Вәзир тагын бер тапкыр учына төкереп алды.

Сабантуй мәйданындагы көрәшчеләргә охшатып, алар кулбашка кулбаш сугып алдылар. Шуннан соң гына, бер-берсенең күлмәген арттан бөреп тотып, билдән алыштылар. Алар, орчык кебек әйләнеп, байтак йөрделәр, икесе дә мышнап төште. Ләкин берәү дә бил бирмәде. Малайларның көч бер чама булса да, Айдар кискә кебек авыр Вәзирне күтәреп чөяргә исәп тотмый иде. Ул берничә тапкыр, үзе кырын егылып, Вәзирне баш аша очырырга маташып карады, әмма теге гөрс итеп аның өстенә авып торды. Хәтта бер вакыт Айдарның үпкәсе бугазына килгәндәй булды.

Алыш тавышсыз-тынсыз дәвам итте. Аяк чалу кебек хәрәмләшүгә берәү дә бармады. Бервакыт исләмәгәндә генә Вәзир Айдарны бөреп алды да, билен өзәрдәй кысып, күкрәгенә күтәрде. Айдарның язгы чебешкедән яңа гына котылып килгән аяклары җирдән аерылды. Алар, таяныч эзләгән шикелле, тыпырчынырга тотындылар, тик таяныч таба алмадылар. Вәзир, кырын егыла биреп, озынча буйлы какча Айдарны баш аша ыргытты. Шул вакыт нәрсәдер пырр-р-р итеп ертылып китте.

Тәгәрәп яткан Айдарның ике учында Вәзир өстендәге зәңгәр күлмәкнең ике итәге иде. Хуҗа өстендә бары тик ике җиңе белән якасы гына эленеп калган. Вәзирнең гадәттән тыш батыр кыяфәтен башта күргән Габдулла кычкырып көлеп җибәрде. Кабыргасы белән очлы ташка барып төшкән Айдар, авыртуын онытып, Габдуллага кушылды:

— Юлбарыс тиресе ябынган баһадир! Ха-ха-ха!

Әлегә бернәрсә дә аңламаган Вәзир, битендәге тирен сөртмәкче булып, күлмәк итәген капшады. Ләкин кулы ялангач корсагына тиде. Ул бары шунда гына Айдар кулындагы чүпрәкләрнең кайдан йолкып алынганына төшенде.

Вәзир менә хәзер я кычкырып елар, я Айдар белән сугыша башлар дип көтәсездер, бәлки. Көтмәгез, көтүегез бушка чыгачак. Вәзир дөньяның вак-төягенә исе китеп бара торган малай түгел. Янә шуны да әйтеп үтәргә кирәк. Кием-салым сандыгы аның бөтенләй үк буш та түгел. Өйдә тагын бер күлмәге бар. Тик менә төсен генә хәтерләве кыен. Дөресрәге, аның төсе юк. Көн ашаган.

Шулай да «Юлбарыс тиресе ябынган баһадир» иптәшләренә кушылып көлмәде. Нигәдер көләсе килмәде. Борынын җыера биреп, горур гына әйтеп куйды:

— Баш сау булса, мал табылыр әле.— Бу вакыт ул үзендә диюне җиңәрлек көч сизде. Автомобиль тәгәрмәченә тын өргән шикелле, кемдер аның беләкләренә көч өреп тутыра диярсең, аның мускуллары кабарып тулыша башлады.

Көрәш әле бетмәгән иде. Вәзир Габдулла каршысына килеп басты:

— Алыш бармы, салыш бармы?

— Алыш та бар, салыш та бар!

Чәмләнүнең чигенә җиткән Вәзир җан ачуы белән Габдулланың чалбар каешыннан эләктереп алды. Ләкин Габдулла көрәшне кабул итмәде. Чөнки «дошманның» өстендә күлмәге дә, билендә каешы да юк иде. Җитмәсә, чалбары да өлтерәп кенә тора. Кыскасы, аның тотыныр нәрсәсе юк иде. Айдар үз каешын чишеп Габдуллага бирде. Башларын чайкый-чайкый сөзешергә килгән яшь үгезләр кебек, гайрәтләнеп, малайлар бер-берсенә ташландылар. Алыш бу юлы баягыдан да яманрак барды. Хәйләкәр Вәзир, бил бирмәскә тырышып, очасын сузып,

гел иелеп йөрде. Ул башта Габдулланың хәлен бетерергә исәп тотты. Ләкин пеше имән кебек Габдулла тиз генә әлсерәп төшә торганнардан түгел иде. Ул Вәзирнең хәйләсенә ирек куйды. Бара торгач, алар алышкан җир, үләне тапталып, тап-такыр булып калды.

Үзәнгә салкынча сыек эңгер төшә башлады. Ә «батырлар», җан-фәрман килеп, һаман алыша бирде. Вәзирнең итләч аркасына бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Ә Габдулланың күлмәгендә әле дым күренми иде. «Уңган атның тире чыкканчы, ялкау атның җаны чыгар»,— дигәннәре шушы буладыр инде, дип уйлады Айдар.

Вәзир көенә йөреп, Габдулла ялкауның чигенә чыкты. Ул, кинәт тезләнеп, Вәзирнең күкрәк астына керде. Күз ачып йомганчы, тегене иңбашына алды да зырылдап әйләнергә тотынды. Әйләнеп-әйләнеп йөрде дә, үзе егылып, Вәзирне баш аша тәгәрәтеп җибәрде. Озак барган каты алыш шулай кинәт кенә тәмам булды.

Нәрсә дип болай көч сынашуларын малайлар онытып та өлгергәннәр иде инде. Арада иң зирәк исәпләнгән Айдар, беренче булып, бәхәснең башын хәтергә төшерде:

— Сайлаулар бетте, — диде ул. — Башлыкка чукмарны тапшырырга вакыттыр инде.

Дүрт күз бер үк вакытта Габдуллага төбәлде. Иң күп отыш, әлбәттә, аның ягында иде. Хәтер калуның яки үч саклауның нәрсә икәнен белми торган Вәзир, беренче булып, Габдулла алдына килеп басты:

— Теләсәң утка, теләсәң суга алып кер! Без синең турылыклы юлдашларың.

— Малайлар,— диде Габдулла,— экияттә дә бит батырлар өчәү булган: берсе йөгерек, берсе төз атучы, берсе көрәшче. Нинди әйбәт булып чыкты.

— Юк инде, иптәшкәй, баш берәү генә була. Син — башлык! Сиңа — ура! — Айдар тауларны яңгыратып кычкырып җибәрде.

Башлыкка хас җитди тавыш белән Габдулла үзенең беренче фәрманын халыкка игълан итте:

— Кирәмәтне коткару өчен төзелгән отрядка «Таган» дип исем кушарга. Ризамы?

— Риза. Артистлар бии торган шундый бию дә бар хәтта, — дип өстәде Вәзир. Айдар баш кына какты.

Шушы тарихи фәрманны кабул иткәннән соң, малайлар, кочаклашып, авыл ягына атладылар. «Таган» бу вакытта үзен мәңге какшамаслык итеп сизә иде.

ВӘЗИРНЕҢ БЕРЕНЧЕ ҺӘЛАКӘТЕ

Уң кулы белән башлыкны кочаклап барганда, мәргәннең күңеле үсеп китте. Унике яшькә кадәр башлык булмый яшәгән икән, моннан соң да яшәр әле. Менә дигән итеп яшәр. Аның каравы, Вәзир «Таган»ның бер терәве. Аннан башка «Таган» «әһ» дигәнче авып төшәчәк. Менә нинди кирәкле кеше ул!

Вәзирнең кемгәдер яхшылык эшлисе, кемнедер куандырасы килде. Ул чалбарының сул кесәсендәге салкын гына каты нәрсәне капшап карады.

— Малайлар, ә, малайлар, туктагыз әле, — диде ул.— Башлыкка коралсыз йөрү килешмәс. Мә, Габдулла, ал. Ул кесәсеннән сөяк саплы борынгы пәке чыгарып Габдуллага сузды.

Башлык белән йөгерекнең дүрт күзе сигез булды. Мондый затлы нәрсәне алар беренче тапкыр күрәләр иде.

— Кайдан кулга төшердең моны?

— Сорашып торма, биргәндә алуыңны бел!

Ләкин башлык бүләкне алырга ашыкмады. Пәке ошады аңа, бик ошады. Тик: «Бу нәрсә Вәзир кулына язып-ялгышып килеп кермәде микән?» дигән шик аны тыеп калды. Чөнки мәргән кулына андый маллар кереп чыккалый иде шул.

— Кайдан алдың, дөресен әйт. Югыйсә пәкеңә бармак очымны да тидермим.

— Дөресе ни инде аның... Биргәч, ал да куй.

— Кайдан алдың диләр сиңа?

— Кайдан дип ни... Дөресе генә... — Вәзир кинәт төелеп калды.

— Нәрсә, дөресе генә?

— Дөресен генә әйткәндә, бая мин аны Шәрифулла агайның сумкасыннан чәлдердем. Нигә, ошамыймыни?— Бу вакыт Вәзир үзенең ялгыш атканын сизеп калган иде инде.

— Урладыңмы? — Башлык ике юлдашын ике якка этәреп җибәрде. Аның күзләреннән усал очкыннар чәчрәп чыкты. — Урладыңмы, эт каешы?

— Урламадым, чәлдердем, — дип акланды Вәзир, — сабы күренеп тора иде.

— Ух, пәке карагы! — Габдулла аңа шап иттереп берне биреп алды. Икенче селтәгәндә аның кулын Айдар тотып калды.

— Кулыңны пычратма шуңа сугып,— диде ул.

Башлык шунда ук үзенең икенче фәрманын игълан итте:

— «Көтүче Шәрифулла агайның сөяк саплы пәкесен урлаган өчен, карак Вәзирне «Таган»нан чыгарып ташларга. Моннан соң аңа кул бирмәскә, сүз кушмаска. Мәсхәрә!»

— Каракка мәсхәрә! — дип кабатлады Айдар.

Вәзир, үзе кылган эшнең бөтен әшәкелеген аңлап, башын түбән иде. Аның күзләре үлән төбендәге бәләкәй генә өненнән сөйрәлеп чыгып килгән кондызга тукталды. Кондыз, тишектән чыккач, тирә-якка сынаулы караш ташлагандай, чак кына туктап торды да үз юлына китеп барды. Аның эшләре Вәзирнекенә караганда шәбрәк иде.

Вәзир өстендәге зәңгәр сәләмәләрне кичке салкынча җил тарткалый. Буй-буй кара эз калдырып, маңгаеннан тир ага, күзләре гадәттәгедән дә ешрак челтләп йомыла. Тик изүендәге зур ак төймә генә, һичнәрсә булмагандай, тыныч кына утыра бирә. Бу минутта Вәзирдәге бердәнбер ак тап әнә шул төймә иде. Шушы вакытта читтән генә берәр кеше карап торса, ул болай дип әйтер иде: «Җир йөзендә хәзер иң кайгылы кеше — Вәзир. Кызганыгыз аны, гафу итегез», — дияр иде. Ләкин аның элекке иптәшләре аңа читтән генә карамадылар. Кызгану, гафу итү кебек йомшаклыкларга алар күңелендә урын калмаган иде.

Бу кичтә «Таган»га өченче фәрман яңгырады:

— «Пәкене хәзер үк хуҗасына илтеп бирергә, Шәрифулла агайның аягына егылып, гафу үтенергә! Әгәр карышса, «карак» дигән яманатын бөтен авылга таратырга!

Башлык икенче фәрманның азагын яңадан кабатлады:

— Каракка кул бирмәскә, сүз кушмаска! Мәсхәрә!

— Мәсхәрә!

Өч терәүнең икесе, кинәт борылып, кайтыр якка китте. Бер-ике адым атлагач, алар артка әйләнеп, Вәзиргә мыскыллы караш ташладылар һәм теш арасыннан төкереп куйдылар.

Өченче «терәү» юлда басып калды. Озак торды ул. Бүген дөнья бетсә, ул башлыкның соңгы фәрманын, бәлки, үтәмәс тә иде. Ләкин иртәгә дә көн бар бит. Шуны уйлап, Вәзир туп-туры ферма ягына йөгерде. Шәрифулла агай, эшен бетереп, кайтырга чыккан иде.

— Менә, агай, Күкрәктауда таптым... — дип ялганлады ул. Дөресен әйтеп, гафу сорарга аның көче җитмәде.

— Вәт, маладис, энем! Гадел егет икәнсең. Рәхмәт үзеңә, — диде Шәрифулла агасы.

Ләкин мондый мактаулар һәм рәхмәтләр «гадел егетне» куандырмады. Чөнки бу юлы бер рәхмәт, бабайлар әйтмешли, мең бәладән түгел, бер бәладән дә коткарачак түгел иде.

ӨЙДӘ ЗАРЫГЫП КӨТКӘННӘР, АХРЫСЫ

Хәзер малайларның өй эчләренә күз салыйк. Кемнән башлыйк икән? Башлыктан башлыйк. Югыйсә хәтере калыр.

Габдулланың өй эчендә өч кеше. Әнисе яз башында ук җәйләүгә күчеп китте. Ул сыер савучы булып эшли. Өйдә алар картинәсе[1] Нәгыймә әби белән икәү генә калдылар. Атасы сугыштан кайтмады, «гармунчы Мөхәммәт» дип, аны авылда әле дә искә алгалыйлар.

Мөхәммәт турындагы яман кәгазь сугыш бетәргә унунбиш көн калгач кына килде. Анда: «Ватан өчен көрәштә батырларча һәлак булды», — дип язылган иде. Әнисе белән картинәсе үксеп-үксеп бик озак еладылар, аннан соң бөтенләй тынып калдылар. Озын көннәр буена бер тапкыр да авыз ачып эндәшмәгән чаклары да булды. Ул вакытта Габдулланың җидесе дә тулмаган иде. Шулай да ул йортка коточкыч бәла килгәнен үзенең бәләкәй генә йөрәге белән аңлады һәм олыларга үз кайгыларын кайгырырга комачауламады. Атасының иске сырмасын бөркәнеп, көннәр буе капка төбендәге яссы таш өстендә утырды. Җылы килде ул яз. Апрель бетмәс борын ук үләннәр яшәрде, кошлар сайрый башлады, күлдә ак чабаклар сикерешеп уйнады. Тик урамнан үтеп-сүтеп йөрүче апалар гына, Габдулла турына җиткәч, аңа тутырып карыйлар да, башларын читкә борып: «Бахыркай...» — дип пышылдыйлар. Кайсылары җиң очы белән күзләрен дә сөртеп алалар. Габдулла ул вакытта әтинең кем икәнен һәм аның нигә кирәклеген белеп җиткерми иде. Шулай да бала күңеленә авыр шом керде.

Бераздан соң Мөхәммәтнең «Батырлык өчен» дигән медале килеп төште. Иптәшләре җибәргән икән.

---

[1] Дәү әнисе, әбисе.

Башк. республиканская
БИБЛИОТЕКА
им. Н. К. Крупской

Менә алтынчы ел инде Нәгыймә әби һәр пәнҗешәмбе көнне кич белән шул медальне акбур белән ялтыратып улының стенадагы бердәнбер рәсеме астына элеп куя.

Габдулла кайтып кергәндә, Нәгыймә әби әлеге медальне ялтыратып утыра иде. Ул авыр көрсенеп куйды да онытын шелтәләргә тотынды:

— Атасыз бала — йөгәнсез ат шул инде. Бөтенләй баш бирми башладың бит. Төнгә чаклы әллә кайда шайтан куып йөрисең. Әнә Якуптан чак кына үрнәк алыр идең. Ничә карама, өй тирәсендә урала. Вакытында ашаган, вакытында эчкән. Өс-башы кыеп карагысыз. Ә син шул Вәзирдән тотам да калмый ияреп йөрисең. Өс-башыңны эшләп беткән!!

— Вәзир үзе миңа ияргә ул, ияртүче булса, — дип мыгырданды башлык.

Нәгыймә инәй әлегә кадәр гади генә малай исәпләнгән оныгының «Таган»га башлык булуын белми иде шул. Белсә, мөгаен, башкачарак сөйләшер иде. Ул һаман үзенекен сөйли бирде.

— Әнә, Якуптан үрнәк алыр идең...

— Куй әле шул Якупны, картинәй!

Якуп бөтен урамда иң юаш һәм тыңлаучан малай иде. Тапкырлыгы чамалы булса да, ул дәрестә дә тырышлыгы белән алдыра иде. Мәктәптә укытучылар, өйдә әниләр һәм картинәйләр малайларны тиргәгәндә еш кына Якупны үрнәк итеп куялар. Өзешеп-тартышып киемнәрен ертсалар да, ызгышып авыз-борын канатышсалар да, малайлар гел шул бер сүзне ишеттеләр: «Әнә, Якуптан үрнәк алыр идең, ичмасам...» Шуның аркасында Якупка «Үрнәк Якуп» дигән кушамат үзеннән-үзе ябышты да куйды. Аны еш кына читкә тибәрделәр, хәтта каккалап-суккалап та алгаладылар. Ләкин Якуп берәүгә дә каршы эндәшмәде, кул күтәреп сукмады.

Габдуллага эләккән шелтә шуннан узмады. Картинәсе өстәл ягына ишарә ясады. Анда буы чыгып торган бер купы тары боткасы утыра иде.

— Башта әйбәтләп кулыңны юып кер, — дип боерды Нәгыймә әби. Үзе тагын да авыр көрсенеп, медальне улының рәсеме астына элеп куйды. Моңа кадәр медальгә Габдулланың бер дә исе китми иде. Бүген ул алдындагы ашын ашап бетергәнче аннан күзен дә алмады. Электр яктысында көмеш медаль нур чәчеп тора иде.

Ни дисәң дә, башлыкны өйдә майлы ботка белән каршыладылар. Ә Вәзирне Корбанбикә җиңги, бөтен авылны яңгыратып, янап каршылады. Корбанбикә җиңгинең холыгы үтә кискен шул. Әгәр сыеры көтүдән кайтмаса, урам буйлап сөрән салып үтә:

— Бүре дә буып екмый бит шул мәлгуньне! Бүре екса, Әҗмәгол муллага хәерләр бирер идем!

Тавыклары бәрәңге бакчасына кереп тибенә башласа, күрше тирә-як янә Корбанбикә җиңгинең ачы каргышын ишетә:

— Үләт тә кырмый бит, ичмасам, шуларны! Көш! Үләт кырса, җаннарым тынар иде! Кө-ө-ш!

Кайтып керер алдыннан Вәзир зәңгәр күлмәкнең калдык-постыкларын салып култыгына кыстырган иде. Ул капкадан керүгә, ачык тәрәзәдән әнисенең ачы тавышы яңгырады:

— Вәзир, дим, малай аламасы! Кайтып кына кер! Бәреп үтерәм хәзер, муеның сынгыры! Йомыш кушсаң, җилкә юка, уен дисәң, дөньясын оныта. Анау Якуптан үрнәк алыр идең чак кына!

Уникe еллык гомерендә янауларны күп ишеткән Вәзир бу юлы да, үзенең күрәчәге алдында баш иеп, җай гына өйгә таба атлады. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: Корбанбикә җиңги телгә усал булса да, Вәзиргә һичкайчан кул күтәрми иде.

Әлеге зәңгәр күлмәкне чоландагы сандык артына яшереп, Вәзир өйгә керде. Атасы каравылга киткән иде. Сугыштан бер аяксыз кайткан Сәмигулла каравылдан башка эшкә ярамый иде. Өч яшькә кече энесе Насип өстәл янында, стенага сөялеп, йоклап утыра. Аның ике урты бүлтәеп чыккан. Күрәсең, ул авызындагы икмәген чәйнәп бетермичә оеп киткән.

— Күлмәгеңне кая иттең, юньсез?

— Мин быел җәй күлмәк кимәскә булдым, әни. Тәнне чыныктырырга кирәк, — дип, Вәзир ипле генә җавап бирде.

— Чыныктырырга түгел, чыбыкларга кирәк сине! Күлмәгең кая?

— Ул чак кына сүтелеп киткән иде, әни, мин аны чоланда калдырдым.

— Ярый, йөре әйдә, исәр Әбдрәфикъ кебек. Ыштаныңны да салып ташла...

— Миңа бит күкрәкне генә чыныктырырга кирәк, әни.

Корбанбикә җиңги, коры салам кебек, дөрләп яна да, кинәт сүнә дә иде. Бу юлы да аның ялкыны озакка бармады.

— Әнә, бүлтерәк бәрән, утыр, аша,— диде ул, йомшый төшеп.

Айдарны өйдә искә алучы да булмады. Тугыз бала арасыннан берәүнең юклыгын сизмәделәр дә. Ул, алачыкка кереп, чүлмәктәге катыкны күтәреп эчте дә печәнлеккә, үз урынына кереп ятты. Яткач та йоклап китте.

Вәзир, болдырга чыгып, байтак кына йолдызларга карап утырды. Арадагы иң тонык йолдыз аның йолдызы кебек тоелды. Нигә бер аңа гына бөтенесе дә тискәре килеп тора икән? Нигә?

Башлыкны да бу төндә бик озак йокы алмады. Бер терәве черек булып чыккан «Таган»ны аякка бастырырга кирәк иде. Өченче терәү кирәк иде таганга. Кемгә ышанырга? Кемгә таянырга?

ӨЧЕНЧЕ ТЕРӘҮ

Габдулла йокыдан уянганда, картинәсе өйдә юк иде. Аның карашы иң элек каршы стенадагы елтыр түгәрәккә төште. Ул сикереп торды да медальгә үрелде. Ләкин кинәт тыелып калды. Чөнки Нәгыймә әби аңа кагылырга берәүгә дә рөхсәт итми иде. Әнисендә күргән иң зур тәңкәдән дә дәүрәк көмеш түгәрәктәге язуны Габдулла яттан белә. Шулай да аны бүген һәр иҗегенә басым ясап, тагын бер кат кычкырып укыды: «За от-ва-гу». Һәм малай кинәт бу сүзләрнең олы мәгънәсенә төшенеп алды. Әлегә кадәр Габдулла аларның мәгънәсе турында уйламаган иде.

«Батырлык өчен!» Димәк, аның атасы батыр булган! Нигә соң аны «Мөхәммәт батыр» дип сөйләмиләр? Күрәсең, белмиләрдер.

Әкияттәге батыр үлсә, ул үзенең кылыч-калканын, ук-җәясен улына васыять иткән. Бәлки, Габдулланың атасы да: «Медалемне улыма бирегез, төсем итеп, күкрәгенә таксын», — дигәндер. Мөгаен, шулай иткәндер. Югыйсә, ул медальне җибәреп тә тормаслар иде.

Габдулла атасы мирасын саклык белән генә алды да күкрәгенең уң ягына такты. Стенага беркетелеп куелган

тутлы күзгә каршысына килеп басты. Башлык кешегә медаль килешеп тора икән. Моннан соң ул гел генә тагып йөртәчәк аны. Картинәй белән килешү әллә ни кыен булмаячак. Бер сукраныр да бер бетәр.

Медален ялтыратып Габдулла урамга чыкканда, капка төбендә турылыклы юлдашы Айдар утыра иде. Күптән килгән булса да, өйгә кереп, башлыкны борчымады. Ул әрсез, сабырсыз малай түгел иде. Медальне күргәч тә Айдарның артык исе китмәде. Киресенчә, әти кешенең медален уенчык урынына тагып чыгуны ул килештереп житмәде. Ләкин, башлыкның хәтерен саклап, бу турыда эндәшмәс булды. Тик, көлемсерәп:

— «Батырлык өчен» медален сул якка, йөрәк турысына тагалар...—дип кенә куйды.

Дустының шаккатмавына аптыраган Габдулла медальне сүзсез генә сул якка күчереп такты. Айдарга аның хәтта беразачуы да килде. «Белмәгәне юк шуның», — дип эченнән сукранып куйды.

— Дөресен генә әйткәндә, Кирәмәт җимерелә дип, Шәрифулла агай арттыра. Бер дә юкка тау җимерелми ул, җир тетрәмәсә...

— Нәрсә син, «Таган»ны җимерер өчен, коткы

таратасыңмы? — дип кызып китте болай да кәефе кырылган башлык. — Шүрлисеңме, куркак?

— Мин куркакмы?

— Син!

— Ә син чәпчемә, — диде Айдар, тыныч кына.— Мин читләтеп кенә әтиемнән сораштым. Кирәмәт башында чынлап та күл бар, ди, тик балыгы гына юк, ди; балыксыз күл ул сукыр күз ише, ди. Белдеңме?

— Нәрсәне?

— Нәрсәне, нәрсәне! Без шунда балык җибәреп үрчетсәк, нинди яхшы булачак. Күлнең эченә җан кереп китәчәк.

— Син шулай дип әтиеңә дә әйттеңме?

— Әйтте ди аңа.

Ток-томалга дустына каты бәрелгәне өчен, Габдулла эчтән үкенеп куйды. Аның тавышы йомшара төште.

— Беләсеңме, Айдар, — диде ул, — Кирәмәт җимерелмәсен дә, ди. Ә кешеләргә бер күл тутырып балык үрчетеп бирсәк, ул да ярап калыр. Иң элек безгә мурда үрергә кирәк. Тоткан балыкны шунда салырбыз. Кылычның аргы башында бик шәп камышлык бар. Балык анда котырып каба.

— Мурданы мин аны «эһ» дигәнче үреп ташлыйм, — диде Айдар.

Малайлар бүген үк Кылычның аргы башындагы таллыкка барып мурда үрергә булдылар. Ләкин өч терәүнең икегә калуы аларны һаман борчый иде әле. Эшне бозды бит тинтәк Вәзир. Ничек кенә булса да, өченче терәүне табарга кирәк иде.

Малайлар көңгер-көңгер сөйләшеп утырганда, Үрнәк Якуп, кулына озын чыбык тотып, күл ягына казлар куып бара иде. Аны күргәч, Габдулла белән Айдар бер-берсенә карашып алды.

— Әй, Якуп, кил әле монда! — дип кычкырды аңа Айдар.

— Казлар куам ич, — диде тегесе, үзе нindидер мескен елмаю белән елмайды.

— Казлар юлны үзләре дә беләләр. Кил диләр бит сиңа!

Кеше чакыргач, Якуп тыңламый булдыра алмады. Чыбыгын сөйрәп, йөгереп килеп тә җитте.

— Утыр! — дип боерды аңа башлык. Якуп тезләнеп җиргә утырды. — Синең батыр буласың киләме?

— Килә дә... Ничек булырга соң? — Якуп, күзләрен ялтыратып, Габдулла күкрәгендәге медальгә карап алды. «Их, бәхетле кешеләр була бит...» дигәндәй көрсенеп куйды.

Башлык Якупны тагын бер кат баштанаяк сынап тикшереп чыкты. Габдулланың сынаулы үткер карашын күргән Якуп, бөршәеп, бәп-бәләкәй булып калды. «Нәрсә эшләтерләр икән?» — дип, тынын да алмый утырды. Әмма шүрләве бушка булды: Габдулла, үз тиңдәше белән сөйләшкәндәй, аңа җитди һәм тыныч тавыш белән мөрәҗәгать итте:

— Синең, Якуп, Күкрәктауга менгәнең бармы?

— Нигә, бар.

— Агарып торган Кирәмәтне күргәнең бармы?

— Нигә, бар.

— Әнә шуның башында түгәрәк күл бар. Ә күлдә балык юк.

— Китче, балыксыз күл буламыни!?

— Була шул. Без — «Таган» дигән отряд — шунда балык җибәреп үрчетергә булдык. Өченче булып безгә кушыласыңмы? Отрядның башлыгы — мин.

— Нинди кызык! — Якуп көлеп үк җибәрде. Башлык соравын кабатлады:

— Кушыласыңмы?

— Әниемнән сорап карармын.

— Мәмәй син, Якуп. Бу — сер. Белеп тор: ассалар да, киссәләр дә, бу турыда һичкемгә әйтергә ярамый.

Габдулла бурычны җайлап кына аңлатып бирде:

— Башта күп итеп уылдыклы балык тотабыз да мурдага җыябыз. Аннан соң чиләкләргә яртылаш су, яртылаш тере балык салып Кирәмәткә шылабыз. Су алыштырам дисәң, юлда адым саен чишмә. Куркыр булсаң, башта ук әйт.

— Тиргәмәсләрме соң?

— Кемнәр?

— Әниләр.

— Тиргәрләр. Бер тиргәрләр дә, бер туктарлар. Зур эш башкарган кешеләрне элек тә аңлап җиткермәгәннәр.

«Таган» алдындагы максатның бөтен бөеклеген Якуп та аңлап җиткермәде, әлбәттә. Аны икенче нәрсә кызыксындырды. Гел читкә тибәрелеп йөргән малайның үз тиңдәшләре арасында буласы, бергә уйныйсы, шая-

расы килде. Шуңа күрә ул, сер сакларга ант итеп, үзе теләп «Таган»га керде. Башлык аңа янә шундый шарт куйды:

— Өч көн эчендә үзеңнең үрнәклегеңне бетер! Төз атарга, агач башына үрмәләргә, кыядан кыяга сикерергә, суда йөзәргә, ишкәк ишәргә өйрән! Бөтенесе дә кирәк булачак.— Габдулла кисәтеп тагын өстәп куйды.— Вәзиргә кул бирмәскә!

— Ә нигә?

— Монысын хәзергә белми торсаң да ярар.

— Ризамы шуларга? Антмы?

— Риза, ант! — диде «Таган»ның яңа терәве.

Иң соңыннан башлык тагын шундый кисәтү ясады:

— Боларның көне миңа калган икән дип масайма. Без сине адәм итәргә чамалыйбыз. Бел шуны.

— Ярый, — дип, Якуп баш какты.

Шушы сәгатьтән алып зур сәяхәткә әзерлек башланды. Сөйләшеп килешү буенча, Габдулла белән Айдар Кылычның аргы башындагы таллыкка мурда үрергә китәргә булдылар. Ә Якуп, үзенең үрнәкле булуын бетерү өчен, авылда калырга тиеш иде. Аңа бирелгән өч көннең беренчесе күптән башланган иде инде.

ДАН ТҮБӘТӘЙ ТҮГЕЛ УЛ

Айдар урамда торып калды, Габдулла, йөгереп, өйгә кереп китте. Бер кыерчык икмәк белән картинәсенең токмач кисә торган пычагын эләктереп, болдырга чыккач кына, Нәгыймә әби кайтып керде. Габдулла пычакны тиз генә артына яшерде. Картинәсе сизми дә калды, ахрысы. Ләкин оныгының күкрәгендәге медальне ул шунда ук күрде. Нәгыймә әбинең йөзе кинәт үзгәреп китте. Аның йөрәгең чәнчү алды, буыннары таралды. Ләкин ул чәпчемәде, кычкырмады. Габдулланың аркасыннан йомшак кына сөйде дә өйгә чакырды:

— Әйдә, улым, өйгә керик әле.

— Без ни... картинәй, Айдар белән Кылыч башына...

— Хәзер китәрсез, Айдар аз гына сабыр итәр.

Өйгә кергәч, Нәгыймә әби оныгын янына утыртты да аркасыннан тагын бер кат сөеп алды.

— Медаль килешеп тора тагын үзеңә.

— Чынлапмы, картинәй?

— Картинәң юкны сөйләмәс. Менә син, биш кыш са-

бак укыган кеше, картинәңә төшендереп бирче: медальне ни өчен бирәләр?

— Батырлык өчен, монда шулай дип язылган да, картинәй. Русча.

— Ярый, монысын аңлаттың, рәхмәт.

— Ә кемгә бирәләр аны?

— Батырларга.

Нәгыймә әби оныгының күкрәгенә ияге белән ишарә ясады. (Безнең якта изге саналган нәрсәгә бармак белән төртеп түгел, ияк белән ымлап күрсәтәләр.)

— Ә моны кемгә биргәннәр?

— Беләсең лә инде, картинәй... Әтиемә.

— Шулай булгач, аны кем тагарга тиеш иде?

— Әтием лә... Ул кайтмады лабаса. Мин ни аны, картинәй, әтиемнең төсе итеп кенә таккан идем.

Нәгыймә әби байтак эндәшми торды. Гадәтенчә, тирән итеп көрсенде. Бәлки, ул кайчандыр шулай яланаякларын урындыктан салындырып утырган Мөхәммәтен исенә төшергәндер. Габдулла атасына охшаган иде. Аның холыклары, сөйләшүе, тыйнаклы елмаюы Мөхәммәтнең балачагын хәтерләтә. Нәгыймә әби оныгына карап кайчак куана, кайчак кайгылары яңарып, эче өзелеп китә. Габдулла да моны аңлый һәм шундый чакларда картинәсенә тагын да ягымлырак булырга тырыша.

Нәгыймә әби өзелгән сүзне ашыкмый гына янә ялгады:

— Алай булгач, тыңла. Батыр үлсә, улына кылычы кала, мәргән үлсә, ук-җәясе кала. Кирәк чакта, ил кушканда, ата коралын балалары кулга ала. Атадан мирас калган сабан белән уллары җир сөрәләр, аның чүкече белән тимер чүкиләр, көрәге белән җир казыйлар. Атадан калган кама бүрекне балалары кия. Әнә синең башыңда да әтиең мәрхүмнең түбәтәе. Әмма атадан калган дан-шөһрәт түбәтәй түгел ул. Балалары аны алмаш-тилмәш киеп йөри алмый. Морҗадан чыккан төтен дөньяны җылытмаган кебек, ата даны да баланы бизәми. Менә үзең әтиеңә лаеклы булып, ил сокланырлык, кешеләр хәйран калырлык эшләр башкарсаң икән...

— Без башкарачакбыз, картинәй. Күр дә тор менә. Үзең дә шаккатарсың әле.

— Күрергә насыйп булсын, — Нәгыймә әби янә өстәп куйды: — Үзеңә ошаса, тагып йөре, медальне әйтәм. Мин каршы түгел.

Габдулла эндәшмәде. Күкрәгендәге медальне алды да рәсем астына кире элеп куйды. Шулчак урамда, ачы итеп, Айдар сызгырып җибәрде. Хәтта аның да чыдамлыгы бетте, ахрысы.

— Хәзер бар инде, — диде Габдуллага картинәсе. — Пычакны югалта күрмә берүк. — Токмач пычагына башка вакыт тотынырга рөхсәт итмәсә дә, бу юлы ул оныгына сүз әйтмәде. Беррәттән ике нәрсә белән аның күңелен төшерәсе килмәгәндер инде.

— Ярый, картинәй, — диде дә Габдулла, атылып чыгып китте.

Оныгы чыгып киткәч, Нәгыймә әби медальне учына алып бераз карап торды. Җиң очы белән аны сак кына сөртеп алды да кире элеп куйды.

«ҮРНӘК»ЛӘР ҖЫЙРАЛА БАШЛАДЫ

Өйгә кайткач, үзенең үрнәклеген бетерү турында Якуп байтак баш ватты. Эшне нидән башларга?

Кече яшьтән үк Якуп һәр адымын үлчәп атларга өйрәнгән иде. Ул үзен һәрвакыт тар гына басмадан атлаган кебек хис итте. Менә-менә ялгыш басар да тәгәрәп төшәр кебек тоелды. Чөнки ана үзенең берданбер баласын артык саклап, кадерләп үстерде.

Бәләкәч Якупка җирдәге нәрсәләр белән танышу тоташ «ярамый»дан башланды. Болдырдан җиргә сикереп уйнарга ярамый, койма башына менәргә ярамый, таш ыргытырга ярамый, күрше Сабирларның Алабаен сыйпап карарга ярамый. Боларны аңа анасы гел шулай талкып торды. Торган саен «ярамый»лар арта барды. Малайлар белән урманга барырга ярамый — адашырсың; күлдә су керергә ярамый — батарсың; тауга менәргә ярамый — кыядан егылып төшәрсең; җәй түбәтәеңне салма — башыңа эссе кабар; яз туныңны салма — томау төшәр. Менә шундый «ярамый»ларның очы да, кырые да булмады. Ә бит аларның бер чиге булырга тиеш иде.

Ана улының әхлагы хакында да күп кайгыртты. Тегенең белән уйнама, моның белән дус булма, тегене өйгә чакырма, моның өенә барма. Тора-бара Якуп белән берәү дә аралашмас булды. Элегрәк яшьтәшләре аны еш кына үчекли, хәтта ара-тирә төрткәләп тә ала торганнар иде. Соңрак аңа бөтенләй игътибар да итми башладылар. Бармы Якуп дөньяда, юкмы — бу беркемне дә

кызыксындырмый иде. Тик әниләр яки картинәйләр генә, гадәт буенча, аны үз балаларына үрнәк итеп куюларын дәвам иттеләр. Ләкин ташбаш малайлар Якуптан үрнәк алырга теләмәделәр.

Габдулла белән Айдар үз яннарына чакыргач, Якуп башта гаҗәпләнде, соңыннан курыкты. Чөнки аны күптән инде берәү дә санга сукмый иде. Килгәч, Якуп шуны төшенеп алды: димәк, әле яшьтәшләре аңардан бөтенләй кул селтәмәгәннәр икән.

Әмма берәүнең бәхетсезлеге икенчегә куаныч китергәнне ул белми иде. Вәзир шундый хурлыкка төшмәгән булса, Якуп һаман «Үрнәк» булып йөри бирер иде.

Менә хәзер аның «үрнәклеге» үзенең соңгы минутларын кичерә. Тик нидән башларга?

Мөгаен, рогаткадан башларга кирәктер. Югыйсә, ул хәтәр корал бөтен малайларның да кесәләрендә йөрмәс иде. Ул, пычак алып, утынлыкка чыкты. Ике җәпле агач эзләп тапты. Хәзер таманлап кисәргә дә, матурлап юнырга гына калды. Кискәгә чабылган балтаны көч-хәл белән суырып алып, ике җәпне таманлап кыскартырга тотынды. Ләкин икенче чабуда бер җәпне ялгыш төбеннән үк чабып ташлады. Башка агач эзләп табарга туры килде. Монысын ару гына килешле итеп чапты. Инде пычак белән рогатканың сабын, җәпләрен юнып шомартырга гына калды. Рогаткасы шәп булырга охшый.

Башта аны ул ап-ак итеп ышкылар, шуннан Вәзирнеке кебек кызыл буяуга буяр. Якупта буяулар җитәрлек. Шуннан әтисенең иске велосипед камерасыннан матур гына итеп резинка телеп алыр, иске итек кунычыннан түгәрәк кенә итеп күн уеп алыр. Әлбәттә, аның әлегә кадәр бу коралны ясаганы юк. Шулай да аның рогатканы күргәне, хәтта тотып караганы бар бит. Башкалар ясаганны ул ясый алмас, дисезме? Ясар, шиксез ясар. Ясар да, йомры гына таш куеп, анау алачык башында утырган песигә төзәп атып та җибәрер.

Шундый татлы уйларга батып, агачын юна гына башлаган иде, үткер пычак, кечкенә генә бер ботакны кисеп, сул кулның баш бармагына килеп тә тиде. Бармактан атылып кан чыкты. Якуп чәрелдәп кычкырып җибәрде:

— Әни!

Ул шунда ук үзенең хатасын аңлап алды. Аяк-кулы канаганда малайларның берсе дә әнисенә йөгереп кайт-

мый, тота да агач черége сибә. Әнә бит шушы утынлыкта ук черек бүрәнә башы ята.

Ул арада Якупның әнисе, чәчрәп, болдырга килеп чыкты:

— Ни булды, балакаем?!

Әнисеннән җәлләтеп торырга бу элекке Якуп түгел иде инде. Ул кулын тиз генә артка яшерде.

— Мин сиңа түгел, әнә теге песигә кычкырдым.

— Котларымны алдың бит, — диде дә ана кире кереп китте.

Бүрәнәдән черек алып, Якуп җәрәхәтенә сипте, күп итеп сипте. Кан башта черек аша да саркып чыкты, ләкин бераздан туктады. Башлаган эшне бетерергә кирәк иде. Әле генә бәла китергән яман пычакны Якуп яңадан кулына алды. Шулай да эш бармады. Киселгән бармак сулкылдап сызларга тотынды.

Якуп «үрнәк»лекне бетерүнең планын үзгәртте. Бүгенгә кул эшкә ярамый икән, аяклар бар. Ул хәзер Күкрәктауның очлаеп торган кыялы җиренә барыр да таштан ташка сикерергә өйрәнер. Башлык куйган бурычны үтәр. Әнисенең сизгер күзләре шикләнеп карамасын дип, ул башта җай гына капка төбенә килде. Койма буенда яткан тупны алып, капкага бәреп уйнаган булды. Бераздан соң тубын капка астыннан урамга тәгәрәтеп чыгарды. Үрелеп, бәләкәй капканы ачты. Капка шыгырдап куйды. Моны ишеткән ана шунда ук ачык тәрәзә янына йөгереп килде.

— Якуп, дим, кая барасың?

— Тубым урамга тәгәрәп чыкты, әни, — диде Якуп.

Әнисе тәрәзә яныннан киткәнче, Якуп, тубын капкага бәреп, урам якта уйнады. Юриме, чынмы — туп тау ягына чыга торган тыкрыкка таба тәгәрәде. Якуп аны куып китте. Туп тәгәри — ул йөгерә. Ләкин туп йомшак үләндә озак бара алмады, туктады. Ә Якуп, бер йөгерә башлагач, тиз генә туктый алмады, Күкрәктауга кадәр барып җитте.

Ул, үрмәләп, очлы кыя янына менде. Анда сандык зурлыгы, хәтта аннан да эрерәк ташлар берсе өстенә икенчесе өелгән. Башка малайлар «сугыш уены» уйнаганда, шушы ташлар арасына посып атышалар. Бу җирдә бик хәтәр. Ялгыш бассаң, егылып, башың тишелүен көт тә тор. Якуп башта бәләкәчрәк ташлар арасында сикергәләп йөрде. Бер тапкыр, сөрлегеп, тезен бәрде.

Әмма бирешмәде, һаман сикерүен белде. Соңрак ул эре ташлар яткан якка күчте.

Авыл ягыннан күз салучы булса, курчак зурлыгы гына бер нәрсәнең кыя итәгендә сикереп уйнавын күреп, гаҗәпләнер иде. Әмма аңа күз салучы булмады. Улының мондый ярамаган эш эшләве әнисенең башына да килмәде. Якуп һаман сикерде дә сикерде. Бу аның өчен уен түгел, ә иң җаваплы эш иде. Малайның, егылып, беләге сыдырылды, маңгае кабарып чыкты. Ярасы күбәйгән саен аның гайрәте артты, йөрәге ярсыды. Шәрифулла агай әйтмешли, бәлки, аның йөрәгенә дә бөркет оялаган булгандыр. Тик әлегә кадәр канат кына җәя алмагандыр.

Якуп белән мавыгып, кичә бездән бик кыен хәлдә калган Вәзирне онытып җибәрдек бит. Әйдә, Якуп үз эшен эшли торсын, без Вәзирләр ягына кагылып үтик. Алар да Якупларга кыйгач кына урам аша торалар бит.

ЙОМРЫ-ЙОМРЫ ЙОМГАГЫМ...

Сугыш елларында да, сугыштан соң да Вәзирләр гаиләсе, башкалар кебек үк, ашау-эчүгә накыс, бик накыс яшәде. Шуңа күрәдерме, Корбанбикә җиңгидә бер сәер гадәт калды. Ул икмәк-тозын, чәй-шикәрен, май-каймагын иреннән, балаларыннан җыеп, яшереп тотты. Сандык, шкаф, келәт, алачык ачкычларын һәрвакыт үзе белән йөртте. Ул гадәтен еллар иминләнә төшкәч тә ташламады. Бөтен ашамлык затын җыйды, яшерде. Әмма чүпрәк-чапрак затына аның исе китмәде.

Өйдә бөтен нәрсә йозаклы булганлыктан, Вәзир бәләкәйдән үк актарынырга, сәрмәнергә өйрәнде. Дүрт-биш яшьлек чакта ук әле ул мендәр арасына яшерелгән арыш көлчәсен тапты. Юк, комсызланып, берүзе генә ашамады. Нәкъ яртысын бүлеп, энесе Насипка бирде. Соңыннан, алачык йозагын кадак белән ачып, икәүләп сөт эчтеләр. Сандыкка да ачкыч яраттылар. Аннан «кунак өчен» генә сакланган өч шакмак шикәрнең берсен чәлдерделәр. Балта белән чабып, шакмакны икегә бүлделәр. Бәләкәйрәге Насипка эләкте. Малайлар бөтен йозакларның да телләрен тиз төшенеп алдылар. Тора-бара йозаклар үз хезмәтләрен үтәүдән бөтенләй баш тарттылар.

Моны Корбанбикә җиңги дә бик тиз сизде. Исәпсез сыйлары юк иде шул аның. Малайларның башына күп каргышлар яуды. Ләкин алар түзем булдылар, эзләнүләрен дәвам иттеләр. Корбанбикә җиңги дә үзенең хәйләсен үзгәртте. Нәрсәләрен ул сандыкка яки чоланга бикләми башлады. Шикәр, конфет кебек нәрсәләр чөйдәге иске тун кесәсенә, очырмадагы пима кунычына яки келәттә гомер буе буш эленеп торган тубалга яшерелде. Май-каймак алачык кар базыннан җимерек мунча мичено күчерелде. Әмма бу чаралар да көткән нәтиҗәне бирмәде. Малайлар бер сер артыннан икенчесен ача бардылар. Әйтергә кирәк, алар бернәрсәне дә умырып алмадылар. Яшерелгән әйберне табу үзе бер мәзәк уенга, кызыклы кәсепкә әйләнде.

Бу уеннан акча дигән зат та читтә торып калмады. Әйтик, мич куышында утырган сукыр лампа астындагы илле тиен акчаны табып, аңа прянник сатып алу, ул прянникны малайлар белән бүлешеп ашау кызык түгелмени? Вәзир аны кызыкка санады һәм шулай эшләде дә. Тиргәүләр, каргаулар, өй түбәсенә яуган боз кебек сикерешеп, читкә тәгәрәп тордылар. Шулай да яшерелгән акчаны табу җиңел эш түгел икән. Бер таптылар, ике таптылар, ләкин өченчегә аларның сәрмәнү сәләтлеге җитмәде.

Бүген Вәзир эзләнүләрен яңадан башлады. Аңа акча бик кирәк иде. Кичәге хурлыкны, иптәшләре белән килешеп, яхшылык белән генә юарга мөмкин. Аның башында бик яхшы бер план туды. Акча табып, лавкадан прянник сатып алырга да, иптәшләрен сыйлап, гафу үтенергә. Безнең якта олылар да бит нахакка хәтерен калдырган кешесен чакырып сыйлыйлар да гафу итүен сорыйлар. Вәзир дә шулай эшләячәк.

Каравылдан кайткан атасы чоланда йоклап ята. Анасы эшкә киткән. Артык шаһит булмасын дип, Вәзир Насипны күл буена бәбкә сакларга куып җибәрде дә, аулак калган өйнең астын-өскә китереп, актарынырга тотынды. Китап эчләрен, тоз савытларын, ишек-тәрәзә башларын тоташ тентеп чыкты. Әмма эзләгәнен таба алмады.

Аның күз карашы әлеге мич куышындагы зур гына йон йомгагына тукталды. Вәзир йомгакны алып кыскалап карады. Ул ашык-пошык кына чорналганга охшый. Үтә йомшак иде. Вәзир йомгакны колагына китереп

тагын да кыскалады. Йомгак эченнән кыштырдау ишетелде. Бу йомгакта ниндидер сер бар иде.

Вәзир йомгакның очын табып алды да сүтеп чорнарга кереште. Аның йөрәге, аю эзенә төшкән сунарчы йөрәге кебек, ярсып тибәргә тотынды. Үзе йомгакны сүтә, үзе сузып-сузып көйли:

— Йомры-йомры йомгагым, күрмәдеңме акчамны? — ди. Шунда ук йомгак өчен җавап та кайтара:

— Йомры-йомры йомгакмын, сүтелеп беткәч әйтермен...

— Әйтмәсәң дә белермен...

Сүтә торгач, йон җеп икенче йомгакка чорналып бетте. Вәзир кулында кат-кат бөкләнгән яшькелт кәгазь генә торып калды. Вәзир аны ашыкмый гына сүтте. Бу өр-яңа биш сумлык акча иде. Аның эченнән тагын бер өч сумлык кәгазь акча һәм бер илле тиенлек көмеш чыкты. Вәзиргә күп кирәкми иде.

— Ата-анасына тимик, безгә баласы да житкән, — дип илле тиенлекне алып чалбар кесәсенә тыкты. Калганнарын элеккечә бөкләп, аларга йомгакны яңадан сүтеп чорнарга тотынды. Үзе чорный, үзе сузып-сузып көйли:

— Йомры-йомры йомгагым, ни күрдең дә ни белдең?

Йомгак өчен җавапны да үзе кайтара:

— Ай күрде, кояш алды, мин берни дә күрмәдем...

Йомгакны элекке хәленә китереп, урынына куйгач та, Вәзир лавкага йөгерде. Илле тиенлек пряник үлчәтеп, ике чалбар кесәсенә тутырды. Тик, нигәдер, сатучы апа аңа бераз шикләнеп карап калды. Әйтерсең, Вәзир илле тиен акча табарлык малай түгел.

Юк, сатучы апа аңа шикләнеп карамады. Ул бөтенләй башка нәрсә хакында уйлады: «Әнисе кер юадыр, күрәсең. Бичаракайның алмаш күлмәге юкмы икәнни?» — дип пошынды ул. Вәзирнең тән чыныктырып йөрүен белми иде шул.

Вәзир прянникны кайтарып абзар читәне арасындагы саламга яшерде. Җае килгәч, тегеләрнең колагына төшерер дә, шуннан алар өчәүләп тауга менәрләр. Иптәшләре: «Ни булыр икән?» — дип көтеп торганда, ул кесәләрендәге сигез прянникны берәм-берәм чыгарып, үлән өстенә куяр, аннан өләшергә тотыныр. Иптәшләренә өчәрне бирер, үзенә икене алыр. Үзенә ул хәтта берне дә алмаска риза. Кунак сыйлауның йоласын белә ул. Шушы уйлар-

дан аның түбәсе күккә тиде. Бу минутларда аннан да шатрак, аннан да бәхетлерәк кеше юк иде.

Вәзир, эре генә атлап, урамга чыкты. Кулларын артка куеп, ялангач корсагын киерә биреп, байтак кына тирә-якка карангалап торды. Ул үзеннән чиктән тыш риза иде.

Шул арада тау тыкрыгыннан, ялт итеп, Якуп килеп чыкты. Аның кабармаган, тырналмаган җире юк иде.

— Әй, Үрнәк, кая бардың? — диде аңа Вәзир.

— Мин Үрнәк түгел, мин — Якуп, дип тартышты тегесе.

— Әллә аю белән алыштыңмы, пәһлеван?

Якуп, иптәшләренә биргән антын шунда ук хәтеренә төшереп, үз юлына китә башлады. Ләкин ул бит «кул бирмәскә» генә ант итте. Сөйләшү ул кул бирү дигән сүз түгел лә. Вәзир яныннан масайган кеше кебек үтеп китүне ул килештермәде.

— Мин бозау эзләдем, — диде ул.

— Маңгаеңны ташка бәрә-бәрә эзләдеңмени ул бозауны?

— Булды инде, — диде Якуп. Бәйнә-бәйнә сөйләп бирүне кирәк тапмады.

— Ну, бизәнгәнсең, әй... Ничава, төзәлер әле. Ямавы өстендә, — дип тынычландырды Вәзир. Аның бүген күңеле күтәренке иде. Кемгә булса да берәр яхшылык эшлисе килеп кенә тора. Шуңа күрә, әллә кайчан күздән төшкән Үрнәк Якупка да, тиң күреп, сүз кушты, игътибар күрсәтте, аның җәрәхәтләрен күреп, хәтта кызганып та куйды. Ләкин бу гына азрак тоелды аңа. Якупны нәрсә беләндер куандырасы килде. Ә Якуп исә бу минутта башкачарак уйда иде: ул Вәзиргә сәлам дә бирми үтеп китәсе урында, хәтер саклап, аның белән сөйләшеп тора, түбәнчелек күрсәтә.

Әгәр Якупның шушы уйларын Вәзир сизеп калса, һичшиксез, Үрнәкнең маңгаена тагын бер-ике яра өстәлер иде. Юк, берни дә сизенмәде Вәзир. Рәхәтлек кичерүчеләр шулай сукыр булалар инде. Киресенчә, Якупка карата аның яхшылыгы артканнан-арта барды. Озак көттермичә, чалбар кесәсеннән рогатка килеп чыкты. Бөтен урамда дан тоткан теге кызыл саплы рогатка иде бу.

— Ошыймы сиңа? — диде Вәзир.

— Нигә, ошый да...

— Кирәкме сиңа?

— Кирәк тә...
— Кирәксә, ал. Мин сиңа бөтенләйгә бирәм.
Якупның кинәт башы әйләнеп киткәндәй булды. Күз алдында ниндидер кечкенә генә кызыл шәүләләр сикерешеп уйнады. Бу вакыт Вәзир кызыл саплы рогатканы аңа сузып тора иде.
— Биргәндә ал! — дип боерды Вәзир. Аның тупас тавышы Якупны айнытып җибәрде.
— Ә мин сиңа резинка туп, янә велосипед звоногы бирермен. Бик тә кызык шылтырый ул, — дип пышылдады Якуп.
— Кирәкми. Бүләкне сатып бирмиләр. Рогаткалар миндә бер дистә ул...
Якуп кыяр-кыймас кына рогаткага үрелде. Алдатмыймы икән дип шикләнде ул. Ләкин киң күңелле, юмарт Вәзир андый вакчыл шаярулардан өстен иде.
Якуп рогатканы алып, калтырана-калтырана, чалбар кесәсенә тыкты.
— Мин дә сиңа... — дип нәрсәдер вәгъдә итәргә тотынган иде, Вәзир аны шып туктатты:
— Кирәкми. Бар, кайт та атарга өйрән!
— Ярый! — дип, теге шунда ук өенә йөгерде.
Якупның китүе булды, авызы колак артына җиткән Гөлнурның Вәзир каршысына килеп басуы булды. Ул култык астына чәчәкле кызыл ситсы төреп кыстырган иде.
— Абау, мәсхәрә, күлмәк тә кимәгән! — дип чәрелдәргә тотынды Гөлнур.
— Бар, юлыңда бул.
— Барам шул. Мин түбән оч Җәмлихә апамнарга ситсы илтәм, ул миңа матур күлмәк тегә, — диде кыз. — Айдар белән Габдулла Кылычның аргы башына китте. Мине ияртмәделәр. Алар миңа тургай баласы тотып кайталар. Икене.
Гөлнур үз юлына китеп барды. Вәзирнең бер агарып, бер күгәреп эче әрнеп калуын ул сизмәде дә. Ач кадерен тук белми шул инде.
Әле генә кукыраеп басып торган Вәзир кинәт бөршәеп калды. Аның кичәге кайгысы яңарып китте: димәк, тегеләрнең Вәзирдән бөтенләй кул селтәүләре рас. Аның Үрнәк Якуп хәленә төшүе, күрәсең, шушыдыр инде.
Бүгеннән алып Якупның йолдызы югарыга күтәрелә башлавын белми иде шул ул. Белсә, үз кулы белән үз коралын аңа тоттырып та җибәрмәс иде.

«Ничек тә җаен табып, бүген кич үк иптәшләрне сыйлап, гафу үтенергә кирәк. Югыйсә дөньяның кызыгы калмады...» — дип уйлады ул.

«ҮРНӘК»ЛӘР ЧЫЛТЫРАП ҚЫЙРАЛА

Якуп кайтып күренгәч, әнисе бер агарды, бер күгәрде. Тамагына төер тыгылып, башта ул байтак эндәшә алмый торды, аннан ачы итеп кычкырып җибәрде:

— Үтергәннәр балакаемны! Үтергәннәр! Еларлык та хәле калмаган бит. Қайсы котырган эте талады шулай, балакаем?

«Үләргә» чамасында да булмаган Якуп тыныч, хәтта бераз тантаналы тавыш белән җавап кайтарды:

— Мин ташта сикереп уйнадым, әни. Бик кызык булды. Шунда ялгыш басып...

Гөлҗимеш апа аны тыңларга да теләмәде, һаман черелди бирде:

— Әлеге Вәзирдер инде, йөзе кара! Қәнсәгә башырып, акылга утыртмасаммы шуны!

Әле генә, шундый юмартлык күрсәтеп, рогатка биргән Вәзирнең гаепсезгә тиргәлүен Якуп тыныч кына тынлап тора алмады. Аның хәтта эче әрнеп куйды.

— Вәзиргә тел тидермә, әни. Ул минем дустым хәзер. Мин үзем егылдым. Үзе егылган — еламас.

Ана торган саен ярсый гына барды:

— Син үзе егыла торган бала түгел. Сөйләмә бушны! Ничәмә әйттем, шул Вәзирләргә аяк басма, дип. Ничәмәләр әйттем...

Анасын ышандырырга җай тапмый торган Якупның башына шундый хәтәр бер уй төште:

— Алайса, әни, — диде ул, — менә күр дә тор. Анау караманың иң очына менәм дә сикереп төшәм. «Ыһ» та итмим.

Шулай дип әйтүе булды, койма буендагы ялгыз карамага таба йөгереп тә китте. Якуп иң түбәндәге ботакка үрелергә дә өлгермәде, анасы аны килеп кочаклап та алды. Әйтергә кирәк, күпме тырышып карамасын, моңа кадәр ул карама башына Якупның бер тапкыр да менә алганы юк иде әле. Бу юлы да менүе бик шикле иде.

— Җүләрләнмә, балам, — диде Гөлҗимеш апа һәм, үз сүзеннән үзенең тәне эсселе-суыклы булып китте. Аның күңелендә бер шик яралды: «Әллә бер-бер төрле

шаукым кагылдымы бу балага? Акылына зәгыйфьлек килдеме, югыйсә?» — дип коты очты. Чынлап та, моңа кадәр һәр адымын анасы кушканча гына атлап өйрәнгән Якупның бу холыгына искитәрлек иде.

Якуп әнисенең кочагында тыпырчынырга тотынды:

— Җибәр, дим, әни! Сикерәм дигәч, сикерәм...

Гөлҗимеш апа тәмам каушап, хәлсезләнеп калды. Бу баланың тилерүе тикмәгә түгел иде.

— Сикерерсең, улым, сикерерсең. Тик иртәгә, яме?— дип тынычландырды ул Якупны. — Ә хәзер өйгә керик. Үзеңне каймак белән сыйлармын. Чәкчәк тә бирермен.

Шундый тәмле нәрсәләрнең исемен ишеткәч, Якуп башкача дуламады. Анасы аны өйгә шул кочагында килеш күтәреп керде. Малай, әлбәттә, анасының куркыныч уйларга батуын сизмәде. «Әнине барыбер ышандырдым», — дип кенә уйлады.

Өйгә кергәч, Якуп бер чынаяк каймак белән ару гына өем чәкчәкне тиз үк селтәп куйды. Булса, тагын да ашар иде, тик сорарга гына кыймады. Гөлҗимеш апа улыннан күзләрен алмый аптырап утырды. «Атасы да китте дә олакты. Кайда барып сугылмак кирәк хәзер?» — дип эчтән өзгәләнде ул.

— Җәрәхәтләрең сызлыймы, балам? — дип сорады ана.

— Юк, — диде улы һәм маңгаендагы куксел-кара шешне сыйпап куйды. Гөлҗимеш апаның йөрәге жу итеп китте. «Чире шулай ук катымы икәнни? — дип әрнеде ул. — Шулкадәр сызлауларны да сизми бит бу бала!»

— Ятып ал, балам, арыгансыңдыр, — диде ана һәм шунда ук урын түшәргә тотынды. Үзенең «Үрнәк» легенә каршы иртәдән бирле көрәшкән Якуп байтак йончыган иде. Шуңа күрә ул карышмады. Түшәгән урынга барып ятты. Яткач та уң ботына ниндидер каты нәрсә тиде. Якуп аны сәрмәп карады. Бу баягы кызыл саплы рогатка иде. Димәк, ул кесәдә ята. Якупның бөтен арыганлыгы берьюлы әллә кайда очып югалды. Ул кинәт сикереп тормакчы булган иде дә... тормады. Йоклаган кеше булып, күзләрен йомды, ә бераздан килештереп хырылдап та җибәрде.

Улының йоклап китүенә тәмам ышанган Гөлҗимеш апа шым гына ишеккә таба юнәлде. Ул авылдан бер чакрым чамасы читтәрәк яшәгән урман каравылчысына барырга карар итте. Каравылчы картның шәһәрдәге врач кызы элекке көнне генә бала-чагасы белән ялга кайткан иде. Гөлҗимеш апа шул врачны чакырмакчы булды.

Ана чоланга чыкты. Менә әкрен генә ишек ачылып ябылды, аннан капка шыгырдап куйды. Якуп шуларның барын да ишетеп ятты. Ул сикереп урыныннан торды да, идәнгә төшкәч, бер-ике кат сикереп алды. Аннан соң тышка чыгып йөгерде. Койма буена килеп посты да әнисенең кайсы якка киткәнен ярык аша күзәтеп торды. Әнисе Вәзирләргә дә кермәде, канцелярия ягына да борылмады, тыкрык аша авыл читенә чыгып китте.

Якуп кызыл саплы рогатканы кесәсеннән суырып чыгарды да аңа шактый ара сокланып карап торды. Егет кулына нинди генә маллар төшми! Хәзер эшкә тотынасы гына калды.

Өй алдына вак таш катыш ком сибелгән. Башта Якуп фуражкасына күп итеп вак таш җыйды. Аннан җайлап кына болдырга менеп утырды. Хәзер атар өчен җай гына урын табып алырга кирәк иде. Ак келәт янындагы багана җәбенә каплап элеп куелган яшел чиләктән дә яхшырак нәрсәне эзләп тә таба алмассың. Якупның карашы шул чиләккә тукталды. Ул, йомры гына бер таш белән рогаткасын корып, төзәргә тотынды. Озак төзәде.

Рогатканың резина кереше, сузыла торгач, нәп-нәзек булып калды. Якуп керешне ычкындырды. Таш үз юлына очып китте, ә кинәт ычкынган кереш бая гына киселгән баш бармакка китереп сукты. Якупның күз алдында кызыл түгәрәкләр сикерешеп уйнарга тотынды. Элегрәк шундый хәл булса, Якуп, рогаткасын атып бәрер дә, елый-елый өйгә йөгерер иде. Хәзер андый чаклар үтте шул.

Бу беренче бәла малайның бары гайрәтен генә арттырды. Авырткан бармагына бер-ике тапкыр өреп алды да яңадан үз эшенә тотынды. Бер атты, ике атты, биш атты, әмма яшел чиләк исе дә китми эленеп тора бирде. Зыңлап та карамады. Якуп, болдырдан төшеп, бер-ике адым келәткә якынлашты. Ул басып атарга тотынды. Өченче таш яшел чиләкнең кабыргасына барып тиде. Чиләк зың итеп калды. Якуп Вәзирдән күп тапкырлар ишеткән сүзләрне кабатлап куйды:

— Бер коймакны майладык!

Ләкин «икенче коймак» бик озак «майланмый» җәфалады. «Инде тидердем», дип бер атуда яшел чиләк кымшанмый да торып калды, ак келәт тәрәзәсенең бер өлгесе челтерәп коелып төште. Бу вакыт шыгырдап капка ачылды. Әмма Якуп аны ишетмәде. Ул, гайрәтләнә төшеп, чиләккә янә атып җибәрде. Бу юлы баягы тәрәзәнең түбәнге өлгесе челпәрәмә килде.

Капкадан килеп кергән Гөлҗимеш апа белән врач, ни әйтергә дә белми, башта аптырап калдылар. Ана үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Балакаем! — Ул, йөгереп килеп, Якупны җитәкләп алды. Бу арада Якуп рогатканы кесәсенә яшерергә өлгергән иде. Ләкин анада рогатка кайгысы юк иде.

— Авыру балагыз шушымы? — дип сорады врач.

— Шушы шул. Минем бердәнбер генәм ул.

Якупны өйгә алып керделәр. Врач аның тамагын, күзләрен карады. Яткырып корсагын капшады. Ике колагына ике резинка эчәк тыгып, ул малайның аркасын, күкрәген тыңлады, шуннан соң тагын бер тапкыр күзләрен карады.

— Балагыз сәламәт. Сау-сәламәт, — диде.

— Сәламәт бала шулай буламыни? Янмаган, күгәрмәгән җире юк бит.

— Чирле булса, сикермәс иде. Сикермәсә, егылмас та иде. Шулаймы, егет кеше? — диде врач.

«Егет кеше» баш какты.

Ана һаман үзенекен сөйли бирде:

— Бу шешләренә, уелган-тырналган җирләренә нинди дару сөртим соң?

— Дару сөртеп торасы юк, төзәлер.

«Эчендә җаны юктыр бу докторның»,— дип уйлады Гөлҗимеш апа. Ә докторның эчендә җаны бар иде. Ләкин юк чирне бар итеп сөрән салучыларны җене сөйми иде аның. Врач, әйберләрен җыеп, кечкенә сумкасына салды да, хушлашып чыгып китте.

— Ярый инде алай булгач,— дип торып калды Гөлҗимеш апа.

Кичкә кадәр ана улын тышка чыгармады, сагалап утырды. Тик көтү кайтыр алдыннан гына, бозау эзләп алып кайтырга дип, тау ягына чыкты. Анда да улын кисәтеп китте: «Тышка аяк атлыйсы булма»,— диде. Үз сүзләренең көченә ышанып җитми, ишекне тыштан элеп тә куйды. Ишекне элмәсә, Якуп, бәлки, өйдә дә утырыр иде. Абзарга ябылган кәҗә бәрәне кебек, ничек бик астында утырсын инде ул? Тәрәзәдән сикереп, Якуп тышка чыкты. Ул башланган эшен беркадәр очлап куярга булды. Чөнки аңа бирелгән өч көннең берсе үтеп бара иде. Әнисе кайтканчы, ул мунча морҗасының очына куелган калай торбаны атып төшерергә дә, уң күрше Сәрбиләрнең нигез өемендә торган балчык чүлмәкне ватарга да, сул күрше Йомабикә әбинең үләи өстендә утырган җиз комганын ямьшәйтергә дә өлгерде. Кыек атудан түгел, аларның һәрберсенә төзәп атты ул. Йомабикә карчык ишетмәде дә, күрмәде дә, әмма Сәрби апа Якупның тетмәсен тетте. «Икенче Вәзир булдыңмы әллә, азгын малай?! Яхшыдан яман туган! Тәртипнең нәрсә икәнен белмәгән юньсез! Менә әнисең генә кайтсын әле...» — диде.

Якуп гомерендә беренче кат «тәртипсез» дигән сүз ишетте. Юк, моңа ул пошынмады. Димәк, хәзер аны берәү дә «Үрнәк Якуп» дип үчекли алмаячак.

КҮЛ ӨСТЕНДӘ БАЛЫК УЙНЫЙ

Көн кичкә авышып бара. Күл өстендә иртәдән бирле йөгерешеп уйнаган вак дулкыннар, ярга сыенып, тынып калганнар. Талчыкканнардыр, күрәсең. «Болар ял итсеннәр әле»,— дигән кебек, җил дә тау ягына китеп

олаккан. Шушы вакытта ул, мөгаен, нарат ботакларын селкетеп йөридер әле. Аның эше бервакытта да бетми.

Ә менә кошлар, ичмасам, вакытын белеп кенә сайрыйлар. Көн эссесендә алар сайрау ягына бик әвәс булмыйлар. Салкын төшә башлагач, аларны тотып та тыя алмассың. Кылыч буендагы һәр куак җыр-моң чәчеп тора. Тыңлап кына өлгер.

Балыклар да иртәле-кичле шаянрак булалар. Әле дә менә, су өстендә исәпсез-хисапсыз түгәрәкләр ясап, балыклар уйный. Кайбер үтә шуклары өскә сикереп чыгалар да, көмеш тәңкәләрен ялтыратып, мактанган булалар. Янәсе: «Күрегез, без нинди матурбыз!» — диләр. Шулай да гамьсезләр алар, балыкларны әйтәм. Әле күлне бер итеп уйнап йөргән чабакларның һәм кызылканатларның байтагына берничә көннән, үз күлләрен ташлап, Кирәмәт башындагы ят күлгә күчәргә туры киләчәк. Һәм алар беркайчан да Кылычка кире әйләнеп кайта алмаячаклар. Бу хакта балыклар бернәрсә дә белмиләр. Хәтта уйларына да китермиләр. Чак кына сизенсәләр дә, шулкадәр үк уйнамаслар иде.

Кошларның эше бөтенләй башка. Аларны син әллә кайдагы урманнарга илтеп ташла, барыбер теләгән чакларында үз куакларына кайталар да киләләр. Менә бит ул җир өстендә яшәү ничек әйбәт. Су астында яшәү ише түгел инде.

Әйдә, балыклар сикерешә, кошлар сайраша торсын. Без яр буендагы тал куаклары арасына күз салыйк. Иң элек без анда бер чем-кара, бер җирән баш күрербез. Гәүдәләрен камыш каплый. Шулай да ул башларның кемнәрнеке икәнен тануы кыен түгел. Карасы: «Мин Габдулла», җирәне: «Мин Айдар»,— дип әллә кайдан кычкырып тора.

«Таган»ның ике терәве тавышсыз-тынсыз гына мурда үреп утыра. Хәзер эш бетеп бара инде. Ләкин шуны әйтергә кирәк: Габдулла ага, башлык булса да, бары кара эшләрне генә башкарырга, дөресрәге, Айдарның ярдәмчесе генә булырга туры килде. Ул картинәсенең токмач пычагы белән чыбык кырып, аларны ботаклардан әрчеп, Айдар алдына салып торды. Бу вакыт ул үзенең башлык икәнен бөтенләй онытып җибәрде. Киресенчә, Айдарга сокланып, аны өстен итеп карады. Хәтта берчакчы: «Ну, оста да икәнсең, малай»,—

дип, иптәше алдында ялагайлана биреп тә куйды. Кулың һөнәр белмәгәч, шулайрак була шул.

Айдарның ярылып беткән йөгерек кулларына чынлап та сокланып туймаслык иде. Нечкә, озын тал чыбыклары аның бәләкәй бармакларында, ефәк тасма урынына, бөгелеп-сыгылып уйный. Әйтерсең лә, ул тал чыбыкларыннан мурда түгел, ә ефәк челтәр үрә иде. Әмма үзенең булдыклылыгы белән ул бер генә тапкыр да шапырынмады, аның йөзендә кукраюның әсәре дә чагылмады. Ара-тирә борынын тарткалап, тик эшли бирде. Чын осталар шундый булалар да инде.

Балыклар сикерешүендә, кошлар сайрашуында, малайлар мурда үрүендә булды. Һәркем үз эше белән мәшгуль иде. Шуңа күрә алар яр башындагы тар сукмак буйлап поса-поса үтеп баручы күлмәксез малайга игътибар да итмәделәр. Малайның ялангач беләкләренә тиеп калган тал яфраклары нәрсәдер пышылдарга итеп карасалар да, аларга колак салучы булмады. Бераз алга киткәч, әлеге малай, йөзтүбән ятып, камыш арасындагы икәүне күзәтергә тотынды. Аның челт-челт йомылып торган үткен күзләре барын да күрде, барын да шәйләде. Бераздан соң ул камыш төбендәге яшь күрәнне бер бәйләм итеп учына җыеп тотты да, ат койрыгы төйнәгән кебек, төйнәп куйды. Безнең урман ягында кешеләр эз югалтмас өчен шулай билге калдыралар. Күрәсең, бу малай да әлеге урынны билгеләп үтәргә булды. Чөнки Кылыч буе зур. Кайда карама, ерып чыккысыз камышлык.

Җәй көне тән яндырып күлмәксез йөргән малайлар сирәк очрамый. Ләкин моның кебек җитез һәм сак хәрәкәт итүчеләр Бөркетледә күп түгел. Аның һәр кыймылдавы: «Мин Вәзир!» — дип кычкырып тора. Үзенә кирәкнең бөтенесен дә барлап, тикшереп чыккач, Вәзир, акрын гына шуышып, артка чигенде. Артта урман. Урманга кереп алгач, ул, куе үлән арасындагы бүдәнә кебек, елт итеп кенә калды.

Ул арада Айдар белән Габдулла да мурданы үреп бетерде. Чынлап та матур нәрсә килеп чыкты. Шулай да Айдар һөнәр ияләренә генә хас бер җентеклелек белән үз эшен тагын бер кат тикшереп чыкты, капкачын бер ябып, бер ачып карады. Шуннан соң гына малайлар чалбарларын салып ыргыттылар. Ике-өч чиләк балык сыешлыгы ауның эченә зур гына ике таш салып,

аны күл эченә, камышлар арасына күтәреп керттеләр. Мурда тиз генә батарга теләмәде. Аны, түбән тарттырып, камыш сабаклары белән бәйләштергәләргә туры килде. Кысла-фәлән кермәсен дип, мурданың капкачын ябып, ныгытып куйдылар. Чөнки безнең балыкчылар беркатлы түгелләр. Алар балыкчылык кәсебенең рәтен беләләр. Бу мизгелдә мурдага язып-ялгышып кергән балыкны көтеп тору юньсезлек булыр иде. Андый адашкан чабакларны гына көтеп утырсаң, җәй үтеп китәр. Иртәгә үк ким дигәндә дүрт кармак белән эшкә тотынырга туры киләчәк.

Әнә бит су өстендә күпме балык чиртә. Малайлар озак итеп күлгә карап тордылар. Аларның күз алдында сикереп уйнаган балык тик кармакка кабар өчен генә ашкына кебек. Бәлки, алар үзләренең яңа күлгә китәчәкләрен сизеп шулай куанышалардыр? Ил гизүне, дөнья күрүне кем генә яратмый соң?

— Уйнагыз, уйнагыз,— диде Габдулла,— уйнар көнегез алда әле.

Һәм үтә мөһим эш башкарган малайлар, чалбарларын киеп, авыл ягына юнәлделәр.

ИРТӘ ЯҢГЫРЛЫ БУЛДЫ

Безнең якта хәтта җәйге яңгырлар да утырып ява. Бер башласа, тәүлек буена талгын гына шыбырдый бирә. Шуңа күрә аны: «Утырып ява»,— диләр. Бу чакта инде җир, майлы ботка ашаган малай иреннәре кебек, ялтырап, рәхәт чигеп ята.

Төн уртасында башланган яңгыр иртә белән дә туктамады. Ләкин барыбер дүрт өйдәге дүрт малай кул кушырып тик утырмады. Кызыл мүкләкне көтүгә куып кайткан уңайда ук Габдулла Айдарларга керде. Алар алачыкта менә дигән дүрт кармак рәтләделәр. Иске ауны кисеп, челтәр капчык юнәттеләр. Ул капчыкның нигә кирәклеген балыкчылар үзләре генә белә. Аннан абзар артына чыгып консерв калаена селәүчән җыйдылар. Җир юеш булгач, бүген селәүчәннәр бик елгырлар. Комсыз балыкны алар үзләре үк чакырып торачаклар.

— Аяктан екты бу яңгыр,— диде Габдулла, уфтанып.— Тапты явар вакыт!

Һәрнәрсәне яхшыга юрарга өйрәнгән Айдар дусын тынычландырырга тотынды:

— Яусын әйдә. Игеннәр үсәр. Явар, явар да туктар. Иртәгә дә көн безнеке бит. Яңгырдан соң балык шәп каба ул!

— Сиңа бөтенесе дә шәп инде, үз башың белән уйламагач,— дип, Габдулла үзенең башлык икәнен хәтергә төшереп алды.— Ә менә кайдан көймә табарга? Көймә! Синең уеңа кергәне бармы шул?

— Ә нигә кирәк ул? Яр башыннан да тупылдап кабып тора.

— Юк инде, маймыч аулаган ыбыр-чыбыр малайлар кебек, яр башыннан кармак салып йөреп булмас.— Габдулла эре генә өстәп тә куйды: — Ул заманнар үткән.

Чынлап та, үзен «балыкчымын» дигән кеше безнең Кылыч буенда яр башыннан кармак салып йөрмәс. Балыкның эресе — күл эчендә, балыкчының юньлесе — күл өстендә булыр.

— Җае табылыр әле,— дип килеште Айдар.— Үрнәкнең карт атасы[1] шәһәрдә кунакта йөри. Тик көймәсен бик зур йозак белән йозаклап киткән. Ачкыч яратып булса...

Башлык яңа фәрманын игълан итте:

— Көймә табуны Үрнәк Якупка йөкләтергә.

Бу вакыт Вәзирләр өендә шундый күңелле сөйләшү бара иде:

— Таңнан торып, бүген коймак изгән идем. Балаларымны бер сыйлыйм әле, ичмасам,— дип тезеп китте Корбанбикә җиңги.— Хәзер дөрләтеп мич ягып җибәрәм.

— Әни, коймакның шома ягын майларсыңмы, әллә шадра ягынмы? — диде Насип.

— Шома ягын да, шадра ягын да майлармын, улым. Бар әле йөгереп кенә алачыктан коры утын алып кер.

— Их, тәмле була икән! — дип, Насип хәтта чәбекәй итеп алды. Ул «әһ» дигәнче, кочак тутырып, утын да кертеп ташлады.

Вәзиргә дә эш калган иде әле:

— Ә син, Вәзир, йөгереп кенә Ямлегөл әбиләрдән таба алып кайт. Ике таба белән чыжлатып кына пеше-

---

[1] Дәү әтисе, бабасы.

реп алырмын. Қара аны, бер аягың анда, икенчесе монда булсын!

Башка йомыш булса, Вәзир, бәлки: «Әнә Насибың барсын», дип, карышып та торыр иде. Әмма бу йомыш карыша торган йомыш түгел иде. Ул яланаягына әтисенең олы итекләрен киеп алды да тышка атылды.

— Коеп яңгыр ява бит. Ялангач йөрмә шулай адәм көлдереп, юньсез! Әнә сырмаңны булса да элеп ал! — дип кычкырып калды Корбанбикә җиңги.

Вәзир әйләнеп тә карамады. Агасы өчен җавапны Насип кайтарды:

— Тән чыныктыра бит ул, әни. Вәзир абыем баһадир кебек көчле булачак. Менә күр дә тор. Теге усал үгез бар бит әле, шуны да чәнчәкәй бармагы белән генә төртеп очырачак ул.

— Бик очырыр әле, салкын тидереп, Кашшаф кебек, кых-кых кыхылдый башласа...

— Баһадирга салкын тими лә ул, әни.

— Менә тагын икенче бер тинтәге. Сиңа гына җитмәгән иде тагын, тәтелдек.

Корбанбикә җиңгинең бүген күңеле күтәренке иде. Уфаның үзеннән килгән күзлекле агай кичә аның эшен мактап китте:

— Тавыкларың җырлап тора, эшең ырап тора икән, килен. Районда алдынгылар рәтенә чыгып барасың бит,— диде.

— Яхшы сүзең — җан азыгы, рәхмәт, агай,— дип куанып калды Корбанбикә җиңги.

Шулай итеп, бүгенге коймакның ачыткычы кичә үк салынган иде. Эшенә мактау ишеткән ана, коймак белән сыйлап, балаларын да куандырырга булды.

Мичкә ут та ягылды. Күмер дә төште. Ялгыз таба күп тапкырлар чыжлап мичкә дә кереп чыкты. Тик Вәзир генә китте дә батты.

КӨЙМӘНЕ ЙӨЗӘРГӘ ӨЙРӘТӘМ...

Барлык йортлар урамга тезелешеп утырган. Бер Ямлегөл әбинең генә кечкенә өе, көтүдән аерылган кәҗә бәрәне кебек, күл тыкрыгының аргы башына, яр читенә чыгып баскан. Аның ике тәрәзәсе күл ягына карап тора. Әллә бер-бер нәрсәгә үпкәләп, бу өй шулай авылга арты белән әйләнгән инде. Алай дисәң, бөтен

Бөркетле Ямлегөл әбине аһ итеп тора. Күрше-тирә аны аш-судан калдырмый.

Бу өйнең үз тарихы, үз язмышы бар. Өйнең төп хуҗасы Мырзабай атаклы балыкчы иде. «Балыкчы урыны су янында булырга тиеш»,— дип, ул нигезен яр буена корды. Бик матур гомер иттеләр, уллар үстерделәр. Күл өсте тып-тын торган беркөнне Ямлегөл әбинең өрлек кебек ике улы берьюлы шушы өйдән сугышка чыгып китте. Икесенең берсе әйләнеп кайтмады. Сугыш басылыр алдыннан гына Мырзабай карт үзе үлеп китте. Дөньялар иминләнә башлагач, колхоз правлениесе Ямлегөл әбинең өен авыл уртасындагы буш урынга күчереп салырга карар чыгарды. Ләкин ул риза булмады: «Картымның, улларымның нигезеннән кузгалмыйм»,— диде.

Әгәр Ямлегөл әби теге чакта өен күчереп салырга ризалашкан булса, бая таба алырга чыккан Вәзир шунда ук әйләнеп кайтыр иде. Ә ул китте дә олакты.

Вәзир, кыптыр-кыптыр йөгереп, тыкрык башына килеп чыкты. Ямлегөл әбинең урам капкасын инде үрелеп ачтым дигәндә генә, аның елгыр күзләре яңгыр челтәре аша күл өстен капшап чыкты. Яр читендә казлар күшегеп утыра. Ә эчтәрәк кемдер көймәдә ишкәк ишеп маташа.

Бәй, бу Якуп лабаса!

Якупның көймәдә йөрүен Вәзир якыннан карап китми булдыра алмады, әлбәттә. Моңа аның көче җитмәде. Коеп яңгыр яуганда Үрнәк Якуп көймәдә йөрсен дә, син шуны исәпкә алмый узып кит, имеш. Юк инде. Мондый кәмитләр сирәк була ул.

Вәзир күл читенә йөгереп килде. Башта бераз эндәшми карап торды. Якуп аның килгәнен дә, торганын да күрмәде. Үз мәшәкате үзенә җиткән иде аның. Ничек кенә ишеп карамасын, көймә алга да китми, артка да чикми, бер урында әйләнеп тик тора. Ә яр ягыннан искән җил аны акрын-акрын гына эчкә куа.

Вәзир чыдамады:

— Әй Үрнәк Якуп, ни эшлисең анда? — дип кычкырды.

Якуп кинәт дерт итеп китте. Ләкин үзен тиз үк кулга алды:

— Картәтиемнең яңа көймәсен йөзәргә өйрәтәм,— дип җавап кайтарды.

— Их, син. Бер ишкәкле көймәне утырып ишәләрмени? Аны аягүрә басып ишәләр. Бас хәзер үк! — дип боерды Вәзир.

Якуп көймә читенә үреләә бирep суга карап алды:

— Су тирән бит...

— Курыкма, юньсез, монда сай, сине дә күмми.

— Мин курыкмыйм ла ул.

Якуп көймәнең нәкъ уртасында утыра иде. Шул утырган җиреннән аягүрә басты. Вәзир аңа яңа команда бирде:

— Артка күч! Уртага басып кем ишкәк ишә, я?

Якуп сак кына артка чигенде.

— Менә шулай,— дип хуплады аны Вәзир.— Хәзер ишә башла. Башта уң яктан иш! Уң яктан дим бит! Уң белән сулны аермыйсыңмы әллә?

Әмма бу юлы Вәзир уң белән сулны үзе бутады. Аңа каршы баскан Якупның уң яктан ишүе, сул булып күренде. Моны Вәзир үзе дә сизеп алды. Тик сер генә бирмәде.

— Ярый, алайса, белгәнеңчә иш,— дигән булды. Якуп ишә бирде, ә яр башыннан команда кабатлана торды: «Аръяктан иш, шулай, шулай! Бирьяктан иш!

Бирьяктан иш! Аръяктан иш!» Әйләнеп-тулганып булса да, көймә ярга якынлаша башлады. Ләкин бу гына Вәзирне канәгатьләндермәде. Ул, ике кулын алмаш-тилмәш селти биреп, боерык өстенә боерыкны яудырып кына торды: «Ишкәгеңне батырма! Киңрәк селтә! Киңрәк! Нигә сәгать теле кебек селкенеп торасың? Туры басып иш! Әнә шулай!»

Якуп һәрбер боерыкны төгәл үтәргә тырышты. Тик инде өйрәнеп җиттем дигәндә генә, көтелмәгән бәла килеп чыкты. Якупның киң генә селтәп, сул яктан ишеп җибәрүе булды, көймәнең кырынаеп китүе булды. Тегеләй чайкалды көймә, болай чайкалды. Көймәдән болайрак Якуп чайкалды. Вәзир: «Утыр!» дип кычкырырга да өлгермәде, Якуп гөперт итеп суга да чумды. Куркуыннан кычкырырга да онытты. Суга егылып төшкәч, Якуп бераз бөтенләй күренми торды. Дулкын өстендә аның шакмаклы кепкасы гына торып калды. Лычма юеш кепка бата башлауга, Якупның башы калкып чыкты.

Вәзир, рогаткадан атылган таштай, күлгә ташланды. Суга керү белән аның итекләре үзләреннән-үзләре төшеп калдылар. Якупның башы күренүгә ул көймә янына барып та җитте. Бу урында күл чынлап та тирән түгел. Шулай да Якупның колагына җитәрлек иде. Йөзә белмәгән кешене батырырга күп кирәкмени.

Вәзир, пешеп җитмәгән ишкәкченең якасыннан эләктереп, ярга таба сөйрәде. Берничә адымнан соң аны бастырып куйды. Якупның йөзе чүпрәк төсле ап-ак иде.

— Күл суы тәмлеме? — дип шаярмакчы булды Вәзир. Тегесе баш кына чайкады. Күрәсең, бигүк тәмле түгелдер.

— Бар, чыга тор,— диде Вәзир.— Мин, чумып, кепкаңны эзлим.

Шунда гына Якуп телгә килде:

— Кирәкми,—диде ул, калтырана-калтырана, — баш сау булса, кепка табылыр әле.

Кепкасы — кепка. Ә менә көймә белән ишкәк икесе ике җирдә, дулкын өстендә акрын гына тирбәлгән булып, әчкә таба уңайларга чамалый түгелме? Шулай шул. Юк инде. Мондый башбаштаклыкка юл куеп булмас. Вәзир, колач салып, яңадан күлгә йөзеп керде. Башта ул ишкәкне барып тотты. Аннан, көймәнең койрыгына чыгып, бер омтылуда менеп тә басты. Якуп, хәле мөшкелрәк булса да, чая иптәшенә сокланмый булдыра

алмады. «Их, шулай йөзә белсәң иде»,— дип ачынып көнләшеп куйды.

Көймә борыны ярга төртелгәч тә, Вәзир сикереп төште. Күл читендә кунычлары гына күренеп яткан итекләрне табып, аларның эчендәге суны түкте. «Әтиемнең итекләре юылды, әйбәт булды,— дип, бу мәшәкатьләргә яхшы нәтиҗә дә чыгарып куйды ул. — Болай булгач, яланаяк кына кайтырга туры килә инде».

Якуп баскан урынында кузгалмый катып тик торды.

— Синнән рәт чыгачак,— дип юатты аны Вәзир. Тик әлегә тәҗрибә ягы гына чамалырак. Ә рәт чыгачак.

— Чынмы?

— «Чынмы?» «Чынмы?», имеш... Минем кайчан бушны сөйләгәнем бар?

— Юк та.

— Ә хәзер ни эшлибез?

— Әллә инде. Картәтиемнең көймәсен урынына илтеп куйыйк.

Малайлар көймәне яңадан суга этәреп төшерделәр.

— Ал ишкәкләрне, түлке ашыкмый иш! — диде оста үзенең өйрәнчегенә.

Күл читеннән генә Якуп көймәне үз урынына алып китте. Вәзир аңа үз киңәшләрен һаман бирә барды. Бер чиркангыч алган Якуп үзе дә бу юлы ишкәк белән кыюрак эш итте. Утыз-кырык адым араны үткәнен сизми дә калды.

Көймәнең чылбырын баганага урап, йозак элеп торганда гына, тыкрык очыннан Якупның әнисе чәрелдәп килеп чыкты.

— Утка да сала, суга да батыра бит бу бала мине! Әлеге Вәзирнең эшедер инде! Су тычканы кебек булгансың бит, балакаем! Бүген үк кәнсәләргә барып башырмасаммы — исемем Гөлҗимеш булмасын. Кайда иттең аның кепкасын? Нигә шул балага каныктың син? Торганы белән бер юлбасар үсә бит!

Гөлҗимеш апа Якупның беләгеннән тотмакчы булды. Ләкин Якуп читкә тайчанды.

— Әни, әгәр Вәзиргә тагын да тел тидерсәң, хәзер үк шушы көймәгә утырам да күл эченә керәм дә китәм. Бер керсәм, мәңге чыгачак башым юк. Бел дә тор!

Гөлҗимеш апа сүзсез генә башын иеп басып торган Вәзиргә зәһәрле караш ташлап алды да сүзен кинәт икенчегә борды:

— Ярый, ярый, тел тидермәм, әйдә, синеңчә булсын, — дип улын җитәкләргә теләде.

— Җитәкләмә мине, — дип карышты Якуп. — Җитәкләмәсәң дә кайтырмын... Тик Вәзиргә тел тидермәстән булсын. Югыйсә...

— Ярый, ярый, бетте дим бит инде.

Ана белән улы кайтыр якка китте. Ике култык астына ике итеген кыстырып, Вәзир күл читендә басып калды. Анда таба кайгысы да, коймак шатлыгы да юк иде инде.

ЯҢГЫРДАН СОҢ

Көн буе яуган яңгыр кичкә таба кинәт туктады. Китмәскә килгәндәй түшәлеп торган болытлар әллә ни арада таралып та өлгерде. Яңгырда юылып тазарган ачык зәңгәр күккә кояш яңадан хуҗа булды. Тик кайдадыр биектә адашып калган вак тамчылар гына сирәк-саяк тамгалап куя. Эре тамчылар җиргә төшкән чакта, алар, уенга мавыгып, һавада торып калганнар, күрәсең. Ни дисәң дә, балалар шул. Уенга бер бирелеп китсәләр, дөньяларын оныталар.

Ул кечкенә тамчылар шундый җылы, ягымлы булалар. Кулыңны сузып торсаң, учыңа сикереп иркәләнәләр, шаяралар. Учыңны йомсаң, бармак араларыннан чыгып качалар. Нинди шаяннар!

— Әһә, каптыңмы кармакка, эләктеңме бармакка! — ди Гөлнур, учына тамган тамчыны йомарлап. — Үзе нинди җылыкай... Анда, кояш янында, җылыдыр шул. — Ул яңадан учын ача да бүтән тамчыны чакыра. — Я там инде, тагын бер генә там инде!

Кызның кечкенә учына тамчы тагын да тама. Кыз шаркылдап көлеп җибәрә.

Гөлнур койма буендагы юан бүрәнәнең бер башына атланган да яңгыр тамчылары белән сөйләшә. Ә бүрәнәнең аргы очында Айдар белән Габдулла байтактан бирле сүзсез утыралар. Малайларның кәефе сүрән күренә. Эше калган кешеләр шундыйрак була инде. Алар бөтен урамны бер итеп шарлавык эчендә чабышып уйнаучы вак малайларның чыр-чуына да, Гөлнурның өзлексез сайравына да игътибар итмиләр. Үз хәсрәтләре үзләренә җиткән.

— Бу Үрнәктән дә уңмадык, — диде Айдар, нindидер

фикерләренә йомгак ясап. — Кирәкмәгәндә гел янда урала, кирәк чакта күзгә дә күренми, мәмәй.

Сүзгә кушылу урынына Габдулла теш арасыннан төкереп куйды. Бу инде ачуның чиген аңлата иде.

Бераздан Айдар тагын сүз кузгатты:

— Я ул шүрләгәндер әле... Ә бабайның көймәсе бердигән. Тамчы да су керми.

Малайларга Якуптан бигрәк көймә кирәк иде.

— Мине башлык дип саныйсыңмы? — диде Габдулла кинәт.

— Саныйм.

— Санасаң, бар хәзер үк Үрнәкне монда чакырып китер.

— Әнисе мине күреп калса, гомердә җибәрәчәге юк. Хәзер чәрелдәргә тотыныр.

Нәкъ шулчак Айдарның колагына Гөлнур тавышы чагылып китте. Ул инде ак таш янында үсеп утырган үлән кыягы белән сөйләшә иде.

Айдар сеңелесен үзе янына чакырып алды:

— Гөлнур, матурым, — диде ул, ялагайланып, — сиңа тургай баласы кирәкме?

— Кирәк тә... Син бит тота белмисең.

— Беләм. Менә күр дә тор. Синең тәти күлмәгеңне котлап берьюлы икене тотып бирермен, яме?

«Я» дип, Гөлнур үз юлына китмәкче иде. Аның баягы үлән кыягы белән сөйләшер сүзе бетмәгән иде әле. Ләкин агасы аны тиз генә коткармады.

— Ул тургай балаларына мин читлек тә ясап бирермен, зәңгәргә буяп. Яме?

— Я, — дип баш какты Гөлнур. — Мин аларга җим сибәрмен. Әйеме?

— Сибәрсең. Шуның өчен син дә минем йомышымны тыңла. Син үскән бит инде.

Бу юлы «үскән» буласы килмәсә дә, Гөлнур каршы эндәшмәде. Чөнки аңа тургай баласы бик кирәк иде. Әлфия исемле кызның тургае булсын да, Гөлнурныкы булмасын, имеш. Ул, теләсә нинди йомышны тыңларга әзер икәнен белдереп, агасының күзләренә карады.

— Бар, матурым, тиз генә Якупны чакырып кил, — диде Айдар. — Тик кара аны, әнисе күреп калмасын. Тиргәшә ул.

Яланаяклары белән пычракны чәпелдәтә-чәпелдәтә, Гөлнур Якуплар ягына таба йөгерде. Барып җиткәч тә

ул дөбердәтеп капкадан килеп кермәде. Койма ярыгыннан башта йорт алдын күзәтеп чыкты. Аның карашы утынлыкта нәрсәдер юнып утырган Якупка тукталды. Тегесе үз эше белән шулчаклы мавыккан, хәтта күтәрелеп тә карамый. Кычкырсаң, әнисенең ишетүе бар. Күп уйлап-нитеп тормый, Гөлнур йодрык зурлыгы таш алып койма аша ыргытты. Таш шап итеп баткакка килеп төште. Якуп сискәнеп китте. Шунда ук койма ярыгыннан кечкенә генә бармак килеп чыкты. Якуп, әлбәттә, ерактан бармакны күрмәде. Шулай да ул, нәрсәдер сизенеп, койма янына килде. Баягы бармак кытыр-кытыр койманы тырнарга тотынды.

— Кем анда? — дип пышылдады Якуп. Урам яктан Гөлнур чәпелдәп җавап кайтарды:

— Мин. Айдар абыем белән Габдулла сине чакырды. Тиз үк килсен, диделәр. Алар безнең бүрәнә өстендә утыралар.

— Ярый, күп теләңә салынма, бар, ычкын!

— Ычкынырмын шул!

Әмма Гөлнур кайтыр якка «ычкынмады». Кинәт аның исенә тәгәләп яткан күлмәге килеп төште. Яңа күлмәкнең хәлен белергә дип, ул Ямлиха апаларына торып йөгерде. Аны бит берьюлы ике шатлык көтә: тәти күлмәк тә, күлмәкнең сөенчесе дә!

Якуп иптәшләрен озак көттермәде. Бәрәңге бакчасы аша башта ул күл ягына чыкты, аннан тыкрык буйлап урамга менде. Ураурак булса да, бу юл куркынычсыз иде. Чөнки шыгырдык урам капкасы һәр кергән-чыкканны Гөлҗимеш апага әләкләп кенә тора.

Габдулла белән Айдарның Якупны ике көн күргәннәре юк иде. Бу арада Якуп бераз тартыла төшкән. Маңгае кара көеп күгәргән, чигәләре, яңаклары кутырлап беткән. Ә шулай да ул элеккегә караганда ничектер үсеп, тураеп киткән кебек күренә.

— Кем үзеңне шулай килештереп бизәде? — дип каршылады аны башлык.

— Үзем.

— Шаяртма!

— Икмәк өсте. Мин кыядан сикерергә өйрәндем. Үзең куштың ла. Минем үрнәклек бетте инде. Тик йөзә генә белмим.

— Бер-ике чиләк күл суы эчсәң, өйрәнерсең әле.

— Өйрәнермен лә ул... — иртән уртлаган күл суыннан аның әле дә күңеле болгана иде.

Бу ике көн эчендә нәрсәләр эшләгәнен Якуп берәм-берәм сөйләп бирмәкче иде дә, башлык үзе сорамагач, сабыр итәргә булды.

— Картәтиең кайчан кайта? — дип сорады Айдар.

— Картәти ни ул... тиз генә кайтмас әле. Ә нигә?

— Аның көймә ачкычы кайда?

— Әллә.

— Син күп «әллә» ләмә әле,— диде башлык, кискен генә, — иртәгә таңнан күлгә төшәргә кирәк. Яктырыр-яктырмас Ямлегөл әбинең мунчасы артында җыелышабыз. Көймәң кичтән үк әзер булсын.

Иптәшләренең йомышы төшүгә, Якуп чиктән тыш шатланды. Моңа кадәр гел читкә тибәрелеп йөргән кешегә «Таган»ның башлыгы үзе эш йөкләтсен дә, шатланырсыңмы, юкмы? Якупның аксыл йөзенә кызыллык йөгерде, күзләрендә моңача күренмәгән якты нур балкыды. Тиңдәшләрең арасында үзеңне тиң сизү бик рәхәт була икән.

— Көймә ни ул... әзер! — Якуп кычкырып ук җибәрде. — Хет хәзер үк утыр да чык та кит.

— Әзер, имеш, анда бияләй зурлыгындай йозак эленеп тора.

— Зур булса да алдакчы йозак ул. Заһитларның алабае кебек, өрми дә, тешләми дә. Картәтием аны болай гына элеп куя.

— Картәтиең азактан тиргәмәсме соң? — дип, Айдар арт якны кайгыртып куйды.

— Тиргәмәс. Картәтием үземнеке әле.

«Таган»ның өч терәве шундый мөһим нәрсә хакында сөйләшеп утырганда, ике кулын кесәсенә тыгып, урамның аръягыннан Вәзир үтеп китте. Үзе ниндидер көйгә сызгырган була. Янәсе, аның боларга исе дә китми. Янәсе, аның эшләнәсе эше эшләнгән, дөньясы тигез, урамга да ул болай гына, тән чыныктырып йөрү өчен генә чыккан.

Ары үтте Вәзир, бире үтте. Ләкин аңа әйләнеп карачы да булмады. Дөресрәге, әйләнеп карадылар, тик сер бирмәделәр. Бүрәнә өстендәгеләрнең берсе дә Вәзир исемен телгә алып сүз башларга батырчылык итмәде. Әйтерсең, урамда аларның элекке дусы түгел, ә керер капкасын тапмый адашкан сарык бәрәне йөри иде. Юк,

адашкан бәрән булса, аны һәркайсысы капка ачып кертер иде.

Югары очтан урап кайтканда, Вәзир урамның бу ягына чыкты. «Таган»га якынлаша башлагач, сызгырудан туктады, кесәләреннән кулларын алды, мөмкин кадәр мескенрәк кыяфәткә керергә тырышты. Ә мескен булу аңа шулкадәр авыр иде. Үз-үзен кызганудан хәтта күңеле тулып китте. Әмма түбәнсенеп булса да аңа иптәшләре белән яңадан аралашырга кирәк иде. Ялгызлыкка чыдый торганнардан түгел иде Вәзир. Малайлар турына җиткәч, ул, бөтен көчен җыеп, сүз кушты:

— Габдулла, — диде ул үзәк өзгеч кызганыч тавыш белән, — теге пәкене мин шунда ук... ышанмасаң, Шәрифулла агайның үзеннән барып сора. Моннан соң кеше әйберенә тисәм, кулым корысын. — Аңа иң элек Габдулланың күңелен эретергә кирәк иде. Айдары исә башлык сүзеннән чыгачак түгел.

Габдулла, тупас кына җавап кайтарырга әзерләнеп, Вәзирнең йөзенә күтәрелеп карады. Ләкин әйтер сүзен әйтә алмады. Аның алдында күзләрен челт-челт йомып торган Вәзирнең бөтен кыяфәте, карашы башлыкның барлык ачуларын берьюлы таратып җибәрде. Аның беләкләренә, күкрәкләренә каз тәне калыккан, өске ирене дер-дер калтырый, корсагында буйдан-буйга тырналган эз ята. Ул эз иртән күлдә Якупның көймәсенә үрмәләп менгән чакта салынган иде.

Габдуллада кызгану тойгысы уянды дисәң генә аз булыр. Малайның йөрәген нәрсәдер, әрнетерлек итеп, чеметеп алды. Аның күз карашына әлеге Вәзир түгел, элекке дус, бәләкәйдән бергә үскән Вәзир килеп басты. Шундый чакта бөтенесе дә берьюлы хәтергә төшә бит ул... Әле мәктәпкә дә йөрмиләр иде бугай. Бервакыт урманда баш киеме чөеп уйнаганда, Габдулланың кепкасы иң өстәге коры ботакка эленеп калды. Күпме таяк, таш ыргыттылар алар, ләкин кепканы бәреп төшерә алмадылар. Ә агач башына үрмәләргә Вәзирдән башка берәүнең дә йөрәге җитмәде. Кепканы ул менеп алды. Төшкән чакта ялгыш басып, үзе дә егылып төште. Хәтта шыншып та карамады ул. «Йөрмәгән — егылмас», — дип кенә куйды.

Габдулла белән Вәзир бергәләп күпме балыкка йөрделәр. Габдулланың балыктан бәхете гел чамалы булды. Вәзир ике-өчне каптырганда, ул берне дә эләктерә

алмый йончыды. Шулай да, Вәзир, кич кайтканда, балыкны, эресен эрегә, вагын вакка аерып, һәрвакыт нәкъ уртага бүлде.

Ә былтыр шундый хәл булды. Кайсыдыр бер яманы күл тыкрыгындагы тирән коега песи баласы ташлап киткән. Песи суга батмаган, ә иң түбәндә чыгып торган бер бурага менеп утырган. Төшкә кадәр кычкырды бичара. Дилбегәгә чиләк бәйләп төшереп карадылар. Песи баласының чиләккә күчеп утырырга башы җитмәде. Олылар да, малайлар да әллә ничаклы булаштылар, тик эш чыгара алмадылар. Шулчак, озын аркан сөйрәп, Вәзир килеп җитте. Бер очын баганага бәйләде дә, арканга тотынып, тирән караңгы коега төшеп тә китте. Башта теге чиләккә утыртып песи баласын мендереп җибәрде, аннан үзе менде.

Менә шул малай хәзер, гаепле башын түбән иеп, иптәшләреннән сүзсез генә гафу үтенә. Габдулла да, Айдар да аны гафу итәргә әзер иде. Әмма «Таган»-ның намусына тап төшергән кешегә карата тиз үк чишелеп китүне башлык урынсыз тапты. «Мондый чакта нечкә тойгылы булырга ярамый», — дип уйлады ул, шуңа күрә дә Габдулла гамьсез, салкын тавыш белән сорау бирде:

— Нәрсә кирәк сиңа?

— Кирәкми.

— Кирәкмәгәч, нигә бу тирәдә ураласың?

— Сез кирәк миңа, — Вәзирнең хәтта тавышы калтыранып китте.

Вәзирне кызганып, Якуп чак-чак елап җибәрмәде. Егетлектә, чаялыкта һәрчак үрнәк булган малайның шундый хәлгә төшүе аның башына сыймый иде. Бөтен урамны дер селкетеп торган Вәзиргә ни булды икән? Иптәшләре нигә аны читкә тибәрәләр? Дусына хөрмәт йөзеннән ул кесәсендәге кызыл саплы рогатканы капшап куйды.

— Теләсәгез тиргәгез, теләсәгез кыйнагыз, — диде Вәзир, — тик бер сүземне генә тыңлагыз, малайлар.

— Я, сал хәбәреңне. Югыйсә, безнең вакыт юк.

— Безнең абзарда бер мәзәк нәрсә бар. Мәзәк дип ни инде, әллә ни мәзәк тә түгел. Әйдәгез шуны барып карыйбыз.

— Я, берәр хәйләдер әле, — дип шик белдерде Айдар.

— Хәйлә түгел лә.
— Ә нәрсә?
— Баргач күрерсез.
«Таган»ның өч терәве бер-берсенә карашып алды. Беренче сүзне, әлбәттә, башлык әйтергә тиеш иде. Һәм ул әйтте дә:
— Барсак та сине сынар өчен генә барабыз. Кара аны, хәйлә-мәйлә корып маташсаң, азак үпкәләштән булмасын... — Башлык үзенең точ йодрыгын күрсәтеп алды.
— Әйтәм бит, теләсәгез асарсыз, теләсәгез кисәрсез...
Габдулла «Таган»га команда бирде:
— Әйдәгез, карап карыйк әле.
Якупны чакыру Вәзирнең чамасына туры килми иде. Аннан да бигрәк, бу урында Үрнәк бөтенләй артык иде. Адәм арасына керергә аңа иртәрәк иде әле.
— Ә сиңа, Якуп, иярмәсәң дә була, — диде ул. Якуп күзләрен мөлдерәтеп Габдуллага карады. Аның өчен җавапны башлык үзе бирде:
— Иярсен. Ул безнең өченче терәү.
Вәзирнең йөрәге жу итеп китте. Әмма сер бирмәде.
— Барсын алайса, — дигән булды. Шунда ук уенда яңа исәп чыгарып алды: «Габдулла белән Айдарга өчәр прәннек тисә, Якуп белән үзенә берәр дә җиткән. Әгәр алай туры килми икән, кеше башына икешәр чыгачак...»

ВӘЗИРНЕҢ ИКЕНЧЕ ҺӘЛАКӘТЕ

Абзарга килеп кергәч, Вәзир үзен хуҗа итеп сизде. Аның тавышы да хәзер көррәк яңгырый башлады. Ни дисәң дә, бүген ул табын хуҗасы булачак.
— Малайлар, — диде ул тантаналы тавыш белән, — сезнең өчен бәләкәй генә сыем бар. Аз булса да, күп дип кабул итегез. Бу сүзләрне табын җыйган чакта аның әнисе еш кына әйтә торган иде.
«Нинди сый булыр икән?» — дип малайларның күзләре елтырый башлады. Тәмле тамак Якуп хәтта иреннәрен чәпелдәтеп, селәгәен йотып куйды.
— Сый дип ни, әллә нинди сый да түгел инде. — Куанычыннан Вәзир бертуктаусыз тәтелдәде. — Кая, Якуп, фуражкаңны биреп торчы.

Якупның башында атасының иске фуражкасы иде.

Вәзир, фуражканы алып, абзарның караңгы почмагына китте. Читән арасына кулын тыгып, сәрмәнергә тотынды. Калган алты күз аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды.

— Әһә, эләктегезме, тәмлекәйләр! — дип, ул читән арасындагы прәннекләрне берәм-берәм фуражкага тутырды. — Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез. Габдулла белән Айдарга өчәр прәннек, калганнарга — берәр, бөтенесенә дә тигез.

Әлбәттә, сый малайлар көткәннән артыграк иде. Уйламаганда прәннек белән сыйлану сирәк эләгә ул. Якуп янә бер тапкыр иренен чәпелдәтеп куйды. Башкаларның да тамак төпләре кытыкланып китте.

Вәзир фуражканың ике читеннән бөреп тотып алды. Кунакларны абзарда сыйлауны ул яхшысынмады. Абзарда ашап утырырга алар бозау түгел лә.

— Әйдәгез, алачык артына барабыз, анда бик аулак, — дип чакырды ул кунакларын. Кунаклар хуҗаның сүзен екмадылар.

Алачык артында яссы, зур таш ята. Табынны шунда корып җибәргәндә, бик яхшы булачак. Менә хәзер хуҗа шул таш өстенә прәннекләрне таратып ташлар. Кунаклар кыстаткан булыр. Вәзир аларны өзлексез кыстап торыр, Якупны, бәлки, артык кыстамас та.

Кунак сыйлаудан да күңеллерәк нәрсә бармы икән бу дөньяда?

Алачык артына чыккач, Вәзир фуражкадагы мөлкәтне таш өстенә чәчеп җибәрде дә бушаган савытны Якупка ыргытты. Әмма кунакларга ни булды? Әле генә елмайган иреннәр кинәт турсайды, ялтырап торган күзләр тонып китте. Ни булды бу кунакларга?

Таш өстендәге сигез прәннекнең берсе генә дә бөтен түгел иде. Кайсысының башы, кайсысының кырые кимерелгән, берничәсе үтәдән-үтә тишелгән. Күрәсең, прәннекне малайлар гына түгел, тычканнар да ярата икән. Ике көн эчендә алар байтак хөрмәт күрергә өлгергәннәр.

— Тычканнан калган сыеңны үзең генә аша инде, — диде башлык.

Вәзир тәмам коелып төште. Кеше башына бәла килүен килер дә, бу кадәр үк килмәс инде.

— Кичә генә кайтарып куйган идем бит, — дип мыгырдады ул, — ышанмасагыз әнә...

Якуп эшне төзәтергә тырышып карады:

— Тычканнан калганны ашасаң, теш нык була икән ул, — дигән булды. Айдар аны шып туктатты:

— Безнең тешләр болай да нык. Синең кебек без шикәр кимереп үсмәгән.

Шулкадәр ымсынып кал да, гарьлегең килерме, юкмы? Малайларның гарьлеге эчләренә сыймый иде.

— Рәхмәт, сыйлаганнан да артык булды, — диде Габдулла һәм «Таган»га шунда ук боерык бирде:— Киттек!

Кунаклар җай гына китеп бардылар. Вәзир башта таш өстендәге прәннекләргә бик озак карап торды. Аннан тегеләрне берәм-берәм бәрәңге бакчасына тондыра башлады. Селтәгән саен эченнән бер үк сүзләрне кабатлады: «Мә сиңа!», «Мә сиңа!», «Мә сиңа!» Бу сүзләрне ул тычканнарга каратамы, прәннекләргә каратамы, иптәшләренә каратамы, үзенә каратамы әйтте, — анысы билгесез иде. Соңгы прәннекне ыргыткач, ул лап итеп таш өстенә утырды да сулыгып елап җибәрде. Күптән инде елау-сыкрауның ни икәнен белмәгән Вәзир озак, бик озак үкседе. Күзләрендә яшьләр беткәнче елады ул.

КАПТЫҢМЫ, БАЛЫК КАРАГЫ!

Көн туганда безнең Кылычкүлне күргәнегез бармы? Юктыр шул. Бер генә тапкыр күрсәгез дә хәйран калыр идегез. Мин бу хакта мактаныр өчен сүз кузгатмыйм. Кылычны да, аның таңнарын да без ясамаган, аларны табигать шулай яраткан. Безнең мактаныр урыныбыз юк. Мин тик шуның өчен генә әйтәм: шушы матурлыкны сез дә күрсәгез иде дим.

Яңа көннең беренче нурлары башта Кылыч аръягындагы биек текә кыяга килеп бәрелә. Шуннан соң, чәчелеп, тирә-якка тарала. Бу вакыт әле күл, ап-ак томаннан сырылган йомшак юрганын баштанаяк ябынып, йоклап ята. Таң яктысы гына аны рәхәт йокысыннан уята алмый, киресенчә, күл юрганын тагын да ныграк бөркәнә төшә. Безнең тау ягында җәйге иртәләр салкынча була шул. Тик кояш үзе күренгәч кенә Кылыч, кыныннан суырып алынган кылыч төсле, ялтырый башлый.

— Озак йоклыйсың, Кылыч, — дип шелтәли аны кояш. — Нинди төшләр күрдең?

— Заманнар имин вакытта Кылыч йокларга тиеш, — дип шаяра күл. — Яхшы төшләр күрдем, кояш. Рәхмәт! — ди.

Кояш аңа башкача сүз кушып тормый, үз юлына китә. Җирдәге һәрнәрсә белән озын-озак әңгәмәләшеп торса, бер көн эчендә күкне ничек урап чыксын ди ул.

Бу чакта күл өсте тигез, ягымлы була. Шул тигезлектә яланаяк йөгереп уйныйсы, сикерәсе килә. Яңа көн туганда, яңа шатлыклар, яңа өметләр дә туа бит. Тик томаннар гына боек, чөнки аларның гомерләре кыска. Шулай да, яр читендәге камышларга, тал куакларына, төнбоек яфракларына уралып булса да, күл янында калырга тырышалар алар. Әмма юкка. Кояш белән томан сыешып озак яши алмый. Моны һәркем белә.

Бөтен авылны бер итеп әтәчләр кычкырганда, өч малай көймәгә утырды. Габдулла белән Айдар печәнлектә бергә йокладылар. Аларның торганын да, киткәнен дә күрүче булмады. Ләкин Якуп тавыш-тынсыз гына ычкына алмады. Ул таң сызыла башлагач та уянган иде. Байтак ара кузгалмый ятты. Аннан соң шым гына киенергә тотынды. Чалбарының бер балагын кигәч тә, әнисе уянды.

— Нигә иртә уяндың, улым? Әллә яман төш күрдеңме?

— Күрмәдем. Без бүген малайлар белән балыкка барабыз.

— Балыкка? Күлгәме? — Гөлҗимеш апа сикереп үк торды.

— Балык күлдә була инде ул, әни.

— Авызыңны да ачма. Шул гына җитмәгән иде тагын!

— Мин иптәшләремә вәгъдә бирдем, әни. Вәгъдәне бозарга ярамый.

— Ярамаганы бар, яраганы бар. Аягыңны да атламыйсың. Менә шул!

— Мин кемнән ким, әни? Бүтәннәргә яраган нигә бер миңа гына ярамый?

— Бүтәннәрдә эшем юк. Минем балам берәү генә.

— Беләсеңме, әни, әгәр иптәшләрем белән бергә җибәрмәсәң, картәтиемнең көймәсенә утырам да бер-

үзем күлгә керәм дә китәм. Менә күр дә тор. Гел генә мине тыеп тора алмассың, мин хәзер зур инде.

Гөлҗимеш апаның күз аллары караңгыланып китте. Ни булды бу балага? Нинди генә зәхмәтләр кагылды икән? Өй тавыгы кебек юаш малай ике-өч көн эчендә бөтенләй кулдан ычкынды. «Әгәр аны хәзер җибәрмәсәң, барыбер сүзен сүз итәр, тәки көймәгә утырып чыгып китәр», — дип уйлады ана.

— Иптәшләрең кем соң? Шул Вәзирдер әле, — диде ул, бераз сүзсез торгач.

— Габдулла да Айдар! — дип горурланып җавап кайтарды Якуп.

Байтак сатулашканнан соң ана елый-сыкрый гына риза булды. Бу Якупның зур җиңүе иде.

— Алдыңны-артыңны карап йөри күр инде, балам, — дип калды ана.

Менә хәзер Якуп, ишкәк тотып, көймәнең артына басты. Габдулла уртага, Айдар очка утырды. Ишкәкче ару-соллы гына ишә башлады. Көймә яр буйлап җай гына алга шуды, бераздан ул бөтенләй томан эченә кереп югалды.

Кылычның аргы башына, мурда турындагы камышлыкка җиткәч, малайлар, көймәне туктатып, кармак сала башладылар. Бу вакытта инде кояш чыгып, күл өстендәге томаннарны куып җибәргән иде.

Башта балык ару чиртте. Айдарга матур гына сигез чабак, ике алабуга, бер кызылканат эләкте. Габдулла да, ваграк булса да, алты-җиде баш каптырды. Якуп кына берне дә ала алмады. Чөнки ул, балык җимне кыймылдаткач та, кармагын кинәт тартып ала иде.

Эләккән һәр балык көймә читеннән суга төшерелгән челтәр капчыкка салына барды. Алар, яңадан күлгә кайттык дип, рәхәтләнеп йөзәләр, сикерешәләр.

Балык каптырганда шауларга ярамый. Ләкин кармак ташлаганда тылсымлы сүзләр әйтү безнең якта йолага кергән. Ул шаулауга да исәпләнми.

— Ир мактаныр, корал эшләр, төкереп салдым, сикереп чык, бер чабагын алып чык, — дип, һәр юлы кармагын сихерли Габдулла.

Теге кызылканат эләккәч, Айдар башта аның авызына төкерде, шуннан такмакларга тотынды:

— Кызылканат, Гизделбанат, әниеңне чакыр, әтиең-

не чакыр, абыеңны чакыр, апаңны чакыр. Чакыр кат-кат! Кызылканат, кап-кап!

— Кап-кап кармакка, эләгерсең бармакка, эләкмәсәң кармакка, әйләнерсең сармакка [1], — дип тегеләргә кушылды Якуп. Күрәсең, балыклар кармакка эләгүгә караганда сармакка әйләнүне яхшыракка санаганнардыр. Алар Якупның янауларына колак та салмадылар. Бәлки, колак салырлар иде дә, аларның колаклары юк бит.

Кояш югарырак күтәрелгән саен, балык сирәгрәк чиртә башлады. Балыкчылар берничә тапкыр күчеп тә карадылар, барыбер балыклар, сүз берләшкәндәй, кармакка кагылмаска булдылар. Артык утыруның файдасы юк иде. Бар балыкны, исән-сау чыгарып, мурдага җибәрергә кирәк. Югыйсә, эчтә дә этләр өрә башлады.

Мурда турындагы камышларны ярып, көймә ярга килеп төртелде. Габдулла белән Айдар, чалбарларын салып, мурда янына ашыктылар. Ул нәкъ үз урынында тора. Тукта, тукта! Мурда тирәсендәге камышлар селкенә түгелме? Малайлар мурданы күреп алды. Ни тамаша бу? Мурда эчендә эре-эре чабаклар, кызылканатлар, алабугалар

[1] Сармак — ахмак.

чәпелдәшеп ята. Унбиш-егерме баш булыр. Ничек кергәннәр алар? Менә сиңа әкият! Мурданың авызы нәкъ элек ябып киткәнчә. Димәк, бу эшне ниндидер адәм кулы эшләгән.

Аудан балык чәлдерү гадәте бар ул бездә. Әле исәрерәк чакта Габдулла белән Айдар үзләре дә кеше авына бер-ике тапкыр кул салганнар иде. Вәзирне әйтеп торасы да юк. Әмма чит мурдага балык китереп салган кешене аларның күргәннәре дә, ишеткәннәре дә юк иде. Бөркетледә мондый хәл булганын хәтерләүче табылмас. Сөйләсәң, адәм ышанмаслык әкәмәт бит бу.

— Менә сиңа, картәнием әйтмешли, бирәсе килгән колына, чыгарып куйган юлына. Әйдә, иш янына куш булыр, — диде Габдулла.

— Я, берәрсе, үземнең мурдам дип, ялгыш салып киткәндер әле, — дигән фикер әйтте Айдар.

— Китте ди сиңа, тот капчыгыңны!

— Алайса бер-бер хәйлә бардыр, — дип янә шик белдерде Айдар.

— Синең өчен бөтенесе дә хәйлә инде!

— Беләсезме, моны кем эшләгән, — диде яр башындагы Якуп. — Балыкчыларга кот китерүче изге рух эшләгән.

— Изге рух, имеш. Җитмәсә, үзе пионер тагын! — дип, Айдар аның сүзен бушка чыгарды.

Малайлар аптырашта калдылар. Хәтта башлык үзе дә моның серенә төшенә алмады. Табышмак чишелми калды.

Икенче көнне балыкчыларның кәсебе уңышлырак булды: ярты чиләк чамасы балык тотып чыктылар. Ләкин аларны кичәгегә караганда да ныграк борчу алды. Мурдада балык тагын да арта төшкән. Җитмәсә, арада өч сары табан да бар иде. Бу юлы малайлар бөтенләй телдән калдылар. Шатланыргамы моңа, әллә кайгырыргамы? Мурдада балык кимесә бер хәл иде. «Ниндидер бер кәкре кулның эше», — диярләр иде. Шик иң башта, әлбәттә, Вәзиргә төшәр иде.

— Малайлар, — диде Якуп, — әйдәгез яхшыга юрыйк. Димәк, безгә кот килгән. Без кешенекен урламаган бит.

— Көч түкми табылган нәрсә барыбер урлау белән бәрабәр ул, — диде башлык.

— Без үзебез тотканнарны таныйбыз бит. Алайса,

чит балыкларны чыгарыйк та җибәрик. Эше дә бетте. — Бу кыю тәкъдимне Айдар кертте.

Шулай да кыю сүздән кыю эшкә күчәргә малайларның кулы бармады. Монау елкылдап торган балыкларны үз кулларың белән кире күлгә җибәр, имеш. Бу ахмаклык булыр иде, әлбәттә.

— Төптән уйлап карасаң, без ни өчен балык тотабыз? Табада куырып, кетердәтеп ашар өченмени? — дигән сорау куйды башлык.

— Кетердәтеп ашар өчен түгел.

— Шулай булгач, тора бирсеннәр. Азактан күз күрер.

— Әгәр харамнан курыксагыз, минем өлештән булыр. Миңа бит барыбер балык капмый, — дип, Якуп җаваплылыкны үз өстенә алмакчы булды.

— Монда синеке, минеке юк! — диде Габдулла. — Бөтенесе дә уртак.

Ничек кенә булмасын, бу маҗара малайларны газапланы.

Әмма безнең балыкчылар ачык авызлардан түгел иде. Өченче көнне алар, бер күл уртасына кереп, бер камышлыкка сугылып, аз гына кармак салып йөргән булдылар да мурдадан байтак читтә ярга чыктылар. Аннары көймәләрен камыш арасына яшерделәр дә, мурда турынарак килеп, куе үлән эченә кереп постылар. Бу хәйләне алар кичә үк корганнар иде. Ничек тә серне чишәргә кирәк иде. Аларның башкача чыдар хәлләре калмаган иде.

Мурда ягыннан күз дә алмыйча, малайлар шактый яттылар. Ләкин шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Камыш сабаклары, агач яфраклары, үлән кыяклары әле иртәнге йокыларыннан уянмаган иде. Ә куак саен үз җырларын җырлаган кошларга малайлар игътибар итмәде. Кошларда аларның эше юк иде.

Менә бервакыт күл өстен шадралатып җил йөгереп үтте. Камышлар: «Нигә уяттың?» — дигән кебек, берберсен тиргәп, кыштырдашып алдылар. Ә агач яфраклары язын йомшак күңелле булалар. Алар тиргәшмәделәр. Киресенчә, бер-берсенә ягымлы итеп сәлам бирделәр. Җил үтеп киткәч, тирә-як янә тып-тын булып калды. Хәтта күбәләк очканы да ишетелә иде.

Бәлки ике, бәлки өч сәгать үткәндер. Малайларның кул сәгате дә, кесә сәгате дә юк иде. Бала чакта сәгать

корсакта була ул. Ачыктыңмы, әнә шул сәгать я иртәнгене, я төшкене, я кичкене ашарга вакыт җиткәнен күрсәтә. Балыкчыларның корсагындагы сәгать, иртәнгене күптән сугып, төшкә табан уңайлый иде. Мондый чакта түземлек дигән нәрсәнең дә рәте китә башлый.

— Юкны бушка бушатып ят инде, — дип пошынып куйды Якуп. Айдар шунда ук түбәтәе белән иптәшенең авызын каплады. Аннан йодрык күрсәтеп алды. Якуп бөтенесен дә төшенде һәм тынып калды.

Якында гына агачны агач кырган тавыш ишетелде. Бу тавышны балыкчы булган кеше тиз таный. Көймә читенә ишкәк тигәндә чыга ул. Аннан соң су чапылдавы, камыш кыштырдавы колакка чалынды. Әмма бу ишкәкче юньле юлда йөрми иде. Ул нәрсәдәндер шикләнеп, үтә сак кылана иде.

Камыш арасыннан, ялгаш зурлыгы гына көймәгә басып, Вәзир килеп чыкты. Ул башта алан-йолан каранып алды. Кеше заты юклыкка ышангач кына көймәсеннән сикереп төште. Көймә койрыгына нәрсәдер таккан түгелме соң? Әйе шул. Вәзир койрыктан салынып йөзеп килгән шул нәрсәне чишеп алды. Ул зур арыш капчыгы булып чыкты. Капчык төбендә нәрсәдер чепелдәргә тотынды. Вәзир капчыкны яңадан суга батырды да мурда янына сөйрәп китте. Димәк, аңа үзе тоткан балык кына җитмәгән. Нинди комсыз! Хәзер мурдадагын чәлдерергә чамалый. Барып чыкмас. Синең һәр адымыңны алты күз күзәтеп тора. Тиеп кенә кара! Кемдер берәү яшерен ярдәм итә, ә Вәзир аларны таларга маташа.

Габдулланың башыннан әнә шундый уйлар йөгереп үтте. Калганнар да каракны фаш итү тантанасын кичерә башлаганнар иде инде. Ух, әләгәчәк тә соң Вәзиргә!

Вәзир мурданың капкачын ачты. Ул ярга арты белән баскан иде. Шунлыктан аның нәрсә эшләгәне күренми иде. Балык чәпелдәгән тавыш ишетелде. Әһә, мурдадагы балыкларны берәм-берәм капчыгына күчерә түгелме соң? Карак, үз эшен җиренә җиткереп, капкачны элеккечә ябып, ныгытып куйды. Нәкъ шул вакыт ярдан Габдулланың зәһәр тавышы яңгырады.

— Каптыңмы, балык карагы!

Вәзир сискәнеп китте. Башта ул карашы белән тирәякны айкап алды. Иптәшләрен күргәч, күзләрен челтчелт йомып, елмаеп җибәрде. Бу елмаю малайларның ачуын гына китерде. Габдулланың килеп җитүе бул-

ды — Вәзирнең яңагына кунып төшүе булды. Айдар да берне өстәп алды. Ләкин Вәзир җавап кайтармады, төп кебек кузгалмый тик торды.

— Балык ашыйсың килдеме, тәмле тамак? — дип ярсыды башлык. — Мә алайса тагын бер чуртанны! — Ул Вәзиргә янә кизәнде. Шул вакыт Вәзир кулындагы буш капчыгын күтәрде. Аның төбеннән шыбырдап су ага иде. Әмма капчык эчендә кыймылдаган нәрсә сизелмәде.

— Кайда иттең балыкны? Безгә үчләшеп, күлгә җибәрдеңме?

— Әнә мурданы кара, ышанмасаң...

Габдулла белән Айдар мурдага ташланды. Күтәреп карасалар, аның төбе туп-тулы диярлек балык иде. Баягыга караганда да күбрәк. Яр башында торган Якуп куанычыннан хәтта сызгырып җибәрде.

Малайлар мурданы кире суга батырдылар. Дөресрәге, ул үзе кулдан төшеп китте дә акрын гына бата башлады. Менә ничек булып чыкты бит! Габдулла белән Айдар, телдән язып, Вәзиргә карап каттылар. Тегесе, «Их сез» дигән кебек, башта елмаеп куйды, соңыннан шаркылдап көләргә тотынды. Көлгәндә аның ялангач корсагы, су өстендә вак дулкын чыгарып, биеп тора иде. Моны күргәч Айдар да көлүеннән тыелып кала алмады. Аларга башлык үзе дә кушылды.

Билдән суда торган өч малай, бөтен күл буен яңгыратып, шулай шактый хахылдадылар. Читтән карап торган берәү: «Бу нинди исәрләр?» — дип уйлар иде.

Барыннан да бигрәк Якуп куанды. Моңа кадәр ул үзен гел ике ут арасында кебек сизә иде.

— Нинди яхшы булып чыкты! — дип сикереп куйды ул.

— Кичә дә син салдыңмы? — дип сорады Габдулла, ярга чыккач.

— Әйе, — дип баш какты Вәзир.

— Элекке көнне дәме?

— Әйе.

— Ә ни өчен?

— Тик, болай. Сезнең мурдагыз тизрәк тулсын өчен. Шулай да йодрыгың каты икән, малай. — Вәзир яңагын сыйпап алды.

— Я, ярар инде, — диде гаебен таныган Габдулла. — Бетсен дә куйсын шунда. Үзең бит...

— Вәзирнең балыктан коты бар, — дип сүзне икенчегә борды Якуп. — Гел эресен генә каптырган.

— Әбер-чәберен мин аның кире җибәрә бардым ла...

Башлыкның башына менә дигән бер фикер килеп төште:

— Таганда ничә терәү була?

Габдулланың бу кинаяле соравын зирәк Айдар шунда ук аңлап алды:

— Ничәне терәсәң, шулчаклы була. Терәүченең үз кулында ул. Теләсәң, унны терә.

Бу юлы башлык гадәтенчә боерык игълан итмәде, ә иптәшләреннән киңәш сорады. Вәзирне нахакка җәберләве өчен ул эченнән бик пошына иде. Шуңа күрә боерык бирергә үзен хаксыз санады. Башлык кеше сабыррак, тотнаклырак булырга тиеш иде.

— Малайлар, — диде ул. — Вәзирне «Таган»га яңадан алсак, нинди әйбәт булыр иде. Кем дә кем риза, шул кул күтәрә.

Малайлар бердәм кул күтәрде. Иптәшләренә кушылып, хәтта Вәзир үзе дә күтәрде. Бөтенесе дә эчтән үтә шат иде. Тик аны тышка чыгаруны һәркем урынсыз санады.

Байтак михнәтләр күргән «Таган» шулай итеп яңадан ныклап аякка басты. Бу юлы ул какшамас дүрт терәүгә таянды.

Малайлар киемнәрен борып киделәр. Вәзир барыннан да элегрәк өлгерде. Аның бар кием — бер кат чалбар иде.

— Нигә, синең башка күлмәгең юкмыни? — дип хәстәрлек күрсәтте башлык. — Яңгырда да ялангач йөрисең.

— Бар, сандыкта ята. Мин, тән чыныктырып, юри күлмәксез йөрим.

Иптәшләре аның тән чыныктыруын белмиләр иде.

Кирәмәт күленә җан керту сәгате ерак түгел иде инде. Юлга чыгу берсе көнгә билгеләнде. Көнне дә көтеп тормыйча, алар таң атканчы ук кузгалачаклар. Ә хәзергә ике көймә авыл ягына таба йөзеп китте. Алдагысында өчәү, арттагы кечкенәсенә берәү утырган. Көймәләр күл уртасына җиткәч, бик моңлы җыр яңгырады. Безнең Айдар шулай моңлы җырлый. «Бигрәк моңлы баласың, бәхетсез булмасаң ярар иде», — ди торган иде аңа картинәсе. Ни эшләп бәхетсез булсын ди

ул? Кешеләр күңелен җыр белән иркәләү үзе зур бәхет түгелмени?

Менә әле дә аның матур тавышы күл өстенә сибелә дә ярларга килеп бәрелә. Юк, ярларга гына түгел, кешеләр колагына барып сугыла да йөрәкләргә үтеп керә:

Кайларда гына булмый, ниләр күрми
Ир-егеткәй белән ат башы...

ҮГЕЗ БЕЛӘН АЛЫШУ

Авыл очыннан көтү күренде. Иң алдан Ямлегөл эбинең сыңар мөгезле ала кәҗәсе килә. Ул — Бөркетле көтүенең алдан йөрүчесе. Хәтта иң шук сарык бәрәннәре дә яланда аны узарга батырчылык итмиләр. Тик авылга кергәч кенә ала кәҗә, бер читкәрәк чыгып, башкаларга юл бирә. Шуны гына көтеп килгән сарыклар, бакырыша-бакырыша, йөгерә башлыйлар.

Бу вакытта инде бөтен урамны яңгыратып вак малайлар шау-шу күтәрә:

— Көтү кайтты! Көтү кайтты!

Бу тавышны ишетеп, һәр өйдән кем дә булса берәү көтү каршыларга капка төбенә чыга. Эштән кайтып өлгермәгән ялгыз кешеләрнең малын күрше-күләннең бала-чагасы каршылый. Безнең Бөркетледә бу гомергә шулай.

Яше-карты, төрлесе-төрле тавышка кычкырып, мал чакыра:

— Бәрәч, бәрәч...

— Кәҗәкәй-кәҗәкәй...

— Һәү-һәш, һәү-һәш...

Бүген көтү каршыларга Габдулла чыкты. Картинәсе өйдә юк иде. Әле бая ук аларга Якуп килгән иде. Ул башлыкка Вәзир биргән рогатканы күрсәтте. Моңа кадәр Якуп теге вакытта Вәзир белән аралашканы өчен шүрләп йөри иде. Хәзер бөтенесе дә үз кешеләр. Габдулла да аңа үпкә сүзе әйтмәде. Киресенчә, Якуп берничә тапкыр төз генә атып күрсәткәч, аны мактап куйды.

Хәзер дә алар көтү каршыларга бергә чыктылар. Габдуллаларның башта ике сарыгы, аннан сыеры кайтты. Ләкин малайлар шунда ук кире өйгә кермәделәр. Бөркетледә һәркем шулай. Үз малы кайткач та борылып кына керми. Калган көтүне озатып җибәрә. Бу

шау-шулы берничә минутның үз яме бар. Кечкенә генә бәйрәмгә охшап кала ул.

Иң ялкау сыерлардан да йөз-йөз илле адым артта калып, түбән очның кызыл күзле коба үгезе кайта. Үзе әллә ни зур да түгел, әмма сөзгәк диләр. Ул үткәндә, бала-чаганың коты оча. Кайсысы капка артына поса, кайсысы киртә башына менә. Менә әле дә, ул якынлаша башлагач, Габдулла белән Якуп, куркып түгел, тик болай гына, киртәгә менеп атландылар. Якуп, кесәсеннән зур гына йомры таш алып, рогаткасын корды. Дөнья хәлен белеп булмый, кирәк булып куюы бар.

Үгез Габдуллалар кырына җиткәндә генә, күршеләрнең өй алдындагы агач ышыгыннан Гөлнур килеп чыкты. Ул, яңа кызыл күлмәген киеп, тегүчедән кайтып килә иде. Гөлнурның түбәсе күккә тигән. Ул бер уңга, бер сулга боргалана, күлмәгенең матур төймәләрен тотып карый, иелеп-иелеп, балитәкләрен сыйпап ала. Үзе нәрсәдер пышылдый. Ә-ә-ә... «Күлмәгең бик матур икән, Гөлнур, котлы булсын. Җылы тәнеңдә тузсын!..» — ди икән ул. Бу сүзләрне аңа әле генә бер апа әйткән иде.

Чынлап та кызыл күлмәкнең килмәгән җире юк иде. Урам уртасыннан гамьсез узып барган коба үгез дә

игътибарсыз гына үтә алмады. Башта ул, туктап, күзләрен акайтып карап торды. Шуннан соң, башын ия биреп, акрын гына Гөлнурга таба атлады. Бу вакыт Гөлнур күлмәгенең түшендәге яшел бәрхет күбәләккә нәрсәдер сөйли иде.

— Гөлнур! Кач! — дип кычкырды Габдулла.

Гөлнур дерт итеп китте, ләкин коточкыч бәла килгәнен аңламады. Чөнки бөтен дөньяда аның өчен матур күлмәктән башка нәрсә юк иде.

Шул арада үгез кечкенә канауны сикереп чыкты да, башын кырын сала биреп, Гөлнурга ташланды. Менә-менә кызыл күлмәкле кечкенә кызны мөгезенә элеп ыргытачак ул.

— Әнекәем! — дип кычкырып җибәрде Гөлнур.

Киртә башындагы Габдулла сикереп түгел, очып төште. Очлы мөгезләр инде Гөлнурга чәнчелде дигәндә генә, ул кызны күтәреп киртә аша ыргытты. Бу турыда эчтә Габдуллаларның кыяр бакчасы иде. Кыз йомшак түтәлгә барып төште. Ярсыган үгез, аз гына чигенә биреп, Габдуллага омтылды һәм аны элеп тә алды. Мөгез аңа кадалмады. Габдулланың гәүдәсе ике мөгез арасына туры килеп кысылып калды. Бу хатасына ачуы килеп шашынган үгез, башын кинәт югары күтәреп, Габдулланы чөеп ыргытты. Ул киртә буенда яткан кырлы таш өстенә барып төште, «әһ» дип бер генә ыңгырашты да бөгәрләнеп ятты. Үгез, тагын артка чигенеп, яңадан ташланырга әзерләнде. Инде омтылдым дигәндә генә, аның кан баскан күзенә чәп итеп таш килеп тиде. Ул ташны Якуп шулай рогаткадан кыек атып туры тидерде. Авыртуга чыдый алмый, коба ерткыч хәтта үкереп җибәрде. Башын чайкый-чайкый бер урында зырлап әйләнде дә урам буйлап ары чапты.

Бу хәл күз ачып йомган арада булды.

Габдулла янына халык җыелды. Ул, авыртудан ыңгырашып җибәрмәс өчен, күлмәк итәген чәйнәп ята иде. Кемдер аны күтәреп алмакчы итте.

— Ах, кулым! — дип кычкырып җибәрде Габдулла. Аның авыз читеннән, нечкә генә эз калдырып, кан ага иде. Моны күргән Гөлнур чыелдап елап җибәрде.

— Кычкырма әле! — дип туктатты аны яңа гына килеп җиткән Айдар.

Җыелган халык гөж килде. Һәркем үз сүзен әйтергә,

үз киңәшен бирергә тырышты. Берәүләр үгезне сүкте, икенчеләр аның хуҗасын тиргәде.

— Мал иясенә охшамый буламы?

— Аның иясе дә елан аягы кискән нәрсә.

— Харап иткән баланы...

— Сүз белән тирмән тарттырып булмас. Чарасын күрергә кирәк.

— Тизрәк больницага озатырга кирәк.

— Ике машинаның берсе өйдә юк, ичмасам...

— Бар, тиз генә ат җигеп кил, Яумбаев!

— Әй, тукта әле, — дип кычкырды Шәрифулла агай җиңел тарантаста узып баручы олы гына бер кешегә. Юлчы, атын туктатып, халык янына килде.

— Бу малайны үгез сөзеп имгәтте,— диделәр аңа.

Юлчы күп төпченеп тормады:

— Салыгыз малайны тарантаска, — диде.

Шәрифулла, сак кына алып, Габдулланы төбенә йомшак печән түшәлгән тарантаска илтеп салды. Габдулла күлмәк итәген йомарлап, тагын авызына тыкты. Аның йөзендә кан әсәре юк иде.

— Я, кайсыгыз бара? — диде ат хуҗасы. — Кузгалырга кирәк.

— Картинәсе өйдә юк бит әле, — диде берәү.

— Үзем барам.

— Үзем...

— Минсез эш чыкмас, — дип, Шәрифулла агай тарантас күчеренә менеп үк утырды.

Айдар белән Вәзир дә сорап карады, тик аларны утыртмадылар.

Әле генә очкын кебек сикереп йөргән Габдулланы, солы капчыгы урынына салып, моннан егерме чакрым җирдәге Култабан больницасына алып киттеләр. Тарантастагылар, күл башын урап, калкулык артына күмелгәч тә, халык таралыша башлады. Габдуллалар капка төбендә тик өчәү генә торып калды. Алар тау аша киткән ерак юлга озак карап тордылар. Әниләрен песи урлап качкан тургай балаларына охшый иде бу өчәү.

ХАТ

Габдулла киткәннән соң, малайлар балыкка төшмәде. Ләкин һәр көн мурдадагы балыкны барлап, җим сибеп кайттылар.

Бу арада авылда әллә ни искитәрлек вакыйгалар булмады. Алай дисәң дә, теге коба үгезне хуҗасы егып суйды. Суймас та иде, халык тавыш күтәрде: «Югыйсә үзеңне үгезең-ниең белән судка бирәбез», — дип куркыттылар.

Янә шул бар икән: Айдар сеңелесе Гөлнурга биргән вәгъдәсен үтәде. Ферма кыегына менеп, канат чыккан ике тургай баласы тотып бирде. Тик агасы читлек ясаганчы, Гөлнур аларның икесен дә очырып җибәрде. Вәзиргә әнисе сары сатин күлмәк тектерде, әмма Вәзир аны барыбер кимәде. «Сабантуенда киярмен әле», — диде. Якупның иске җәрәхәтләре төзәлә барды, яңалары өстәлә торды. Чөнки аның менмәгән кыясы, үрмәләмәгән агачы, сикереп чыкмаган чокыр-чакыры калмады. Моңа хәтта Гөлҗимеш апа да күнегә башлады.

Габдулланың имгәнү хәбәре җәйләүдәге әнисенә дә барып җитте. Ул икенче төнне өзгәләнеп кайтып килде. Җиккән атын да тугармый, шунда ук Култабанга чапты. Аны авылда күрүче дә булмады. Улының тере икәнен күргәч кенә, ана бераз тынычланды. Габдулланың ике кабыргасы, сул кулы сынган иде. «Яшь сөяк тиз үк ялганыр, — диде доктор. — Малаең чыдам икән. Ай-һай-һай, шәп егет булачак». Кешене үлемнән коткарган кыю улы өчен ана горурланып та куйды. «Нәкъ атасы инде», — дип уйлады ул.

Авылда да Габдулланың исеме берничә көн телдән төшмәде. Гөлнурның әнисе, өй борынча йөреп, Габдулланы елый-елый мактап сөйләде: «Мәңге түләп бетергесез бурычлыбыз инде ул балага», — диде. Габдулла кайткач сыйлармын дип, йомырка җыеп, май язып куйды.

Бөтен авырлыкны сүзсез кичерергә өйрәнгән Нәгыймә әби бу юлы да кешегә белдереп аһ-ваһ килмәде. Әмма эчтән бик өзгәләнде. «Карап торган бердәнбер онызымнан торып калмасам ярар иде», — дип әрнеде ул. Яңа кайгысы никадәр генә зур булмасын, ул пәнҗешәмбе көнне кич улы Мөхәммәтнең «Батырлык өчен» медален акбур белән ялтыратып куярга онытмады.

Ун көн дигәндә картинәсенә Габдулладан хат килеп төште. Үзе укый белмәсә дә, Нәгыймә әби хатны ачмый түзә алмады. Ул сак кына конвертның җилемен куптарды. Хатны чыгарып әйләндереп-әйләндереп карап торды. Шуннан гына оныгының дусларын хат укырга чакырды. Арада иң җиренә җиткереп укучы Якуп иде. Тыңлаучы-

лар тезелешеп сәкегә утырдылар. Якуп каршыга басты. Ул тамагын кырып алды да укырга тотынды.

«Хат башы — яз каршы. Кадерле һәм хөрмәтле картинәм! Әлегә кадәр ни өчен хат язмый тордың, дип сорасаң, җавап бирәм. Минем ике кабыргам, сул кулым сынган булып чыкты. Янә өч көн кан төкереп яттым, эч-бавырым кузгалган икән. Хәзер урынына утырды инде. Мине караватка салып куйдылар да бер атна торгызмадылар. Тышка чыгасы килгәндә дә кузгатмадылар, аска чынаяк савыт куеп кына тордылар. Мин оялып беттем. Сул кулымны, ак балчык сылап, катырдылар. Хәзер кузгатып карыйм да кулым яман авыр. Кулымның сызлавы бетте. Тик балчык астында кычытып аптырата. Тын алганда сул кабыргам чәнчешә, чәнчешсә дә элекке кебек кыен түгел. Мин тынымны чамалап кына алырга тырышам.

Күлмәгемне, чалбарымны салдырып алдылар. Галәмәт зур ак күлмәк-ыштан кидерделәр. Ыштанымны сестра апа яра бәйли торган озын тар марля белән буып куйды. Больницада бик эссе. Чебен кермәсен өчен, тәрәзәләргә челтәр куйганнар. Чебен барыбер керә. Ашап туйгач, көн дә җимеш суы эчерәләр. Компот диләр аны. Бик тәмле була икән ул компот.

(Соңгы сүзләрне укыганда, Якуп ирексездән иреннәрен чәпелдәтеп алды.)

Докторлар ифрат әйбәтләр, картинәй. Иң баш доктор минем белән гел шаярып сөйләшә. Бүлмәгә килеп кергәч тә: «Шәпме, батыр!» дигән була. Минем чәчемне машинка белән алдылар. Ул машинка тамчы да авырттырмый икән. Аллабирде картатай башымны пәке белән кырганда, күздән утлар күренә торган иде.

Бер бүлмәдә без өчәүбез. Тәрәзә янында яткан агай исерек көе кызыл аракы дип караңгыда ялгыш сыек җилем эчкән. Кәгазь ябыштыра торган җилем. Аның эче эчкә

ябышкан. Радио әрҗәсе янындагы агайны урман кискәндә агач баскан. Ул телен тешләп өзгән. Хәзер сөйләшә алмый.

Мин монда бик ялыктым инде. Кайтасым килә. Күлмәк белән чалбарны бирсәләр, бүген үк кайтып китәр идем.

Картинәй, бу хатны, мөгаен, я Вәзир,я Айдар, я Якуп укып бирер. Кем укыса да әйт: теге балыкларның хәлен белеп торсыннар, җим илтеп сипсеннәр. Ачтан үләрләр югыйсә. Әниемнән сорарга да онытканмын: Гөлнурның аяк-кулы исәнме?

Картинәй, мин сиңа бәләкәй генә күчтәнәч җыйдым: унбер печенье, сигез кәнфит, ун шакмак шикәр. Бу үз авызыннан өзә икән, дип уйлама тагын. Монысы — артып калганы.

Хат ахырында шуны язам: бөтен нәсел-ыруга, дус-ишкә аермыйча миннән сәлам тапшыр. Үзең белән әнигә, янә Вәзиргә, Айдарга, Якупка аерым-аерым сәлам. Минем өчен хәзер борчылма инде, картинәй. «Батыр ярасыз булмас», — диде доктор.

Шуның белән хат тәмам. Алучысы картинәм, язучы Габдулла.»

Хатны тыңлап бетергәч, Нәгыймә әби Якупка буш конвертны сузды:

— Мә әле, улым, моның артына да нәрсәдер язган түгелме?

Конверт артына шундый сүзләр язылган иде:

«Бу конвертны теге җилем әчкән агай бирде. Маркасы да өстендә».

Нәгыймә әби үзе хат тыңлады, үзе Габдулланың унике еллык бөтен гомерен күз алдыннан кичереп утырды. Әле күптәнме соң ул оныгы турында: «Кайчан тәпи басар?», аннан: «Кайчан сөйләшә башлар?», «Кайчан мәктәпкә керер?» — дип хыяллана торган иде. Менә хәзер аның оныгы җир аягы-җир башы җирдән, Култабан авылыннан, килештереп хат язып җибәргән. Габдулланың гомерендә беренче язган хаты иде бу.

ҖАВАП

Җавап язуны озакка сузмадылар. Габдулланың язылып бетмәгән дәфтәреннән кәгазь ертып алдылар. Ләкин өйдә каләм заты да, язу карасы да табылмады. Башлык сакчыл кешеләрдән түгел иде. Әлеге Якуп йөгереп өйдән каләм алып килде. Хатны яза башлаганчы ук, Нәгыймә әби, кулына акча тоттырып, Айдарны почтальонга марқалы конверт алырга җибәрде.

Хатны Вәзир язды. Чөнки аның язуы арада иң матуры иде. Язды дигәч тә, үз башыннан уйлап чыгармады. Аңа Нәгыймә әби барын да тезеп әйтеп торды.

— Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле булып торучы оныгым Габдулла! Яздыңмы? — дип сорады Нәгыймә әби.

— Яздым да, «гыйззәтле» сүзендә ике «з» языйкмы, әллә берәү дә җиткәнме?

— Ничәү кирәк, шулкадәр яз. Җитми калганчы, артык булсын, икене куй.

— Нәрсә дигән сүз ул «гыйззәтле»?

— Мин үзем дә белеп җиткермим аны. Әмма хат башына аны куймый килешми. Син күп төпченмә, әйткәнне язып утыр. Әйдә, баштан башлыйк:

— *Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле булып торучы оныгым Габдулла!*

Бер кәлимә сүземне әйтердән элек, бер генә бәйләм чәчәк кебек, сәламнәремне сиңа күндереп калыйм, дим. Син яткан Култабан якларыннан күзләрен дә алмый зарыгып көткән картинәеңнән күптән-күп сәлам, янә Җаек буенда җәйләүдә сыер савып синең өчен янып-көеп яшәүче әниеңнән сәлам. Дәхи әтиеңнең дә, әниеңнең дә кендеген кисеп, өйдә дә, илдә дә хөрмәт күреп торган Ямлегөл әбиеңнән сәлам. Картатаңның сунардаш дусы Аллабирде картатаңнарның бөтен өй эченнән сәлам. Олы башын кече кылып, юк вакытын бар күреп, сине духтырга үз куллары белән илтеп тапшырган Шәрифулла абзаңнан сәлам. Атаңның иң якын дусты, хәзергесе көндә кәнсәдә счет төймәсе тартып утыручы чатан Сәхипгәрәйдән сәлам. Ике як ут күршеләрдән өй эчләре белән сәлам. Сәлам шуның белән тәмам.

— Ә бездән? — диде Якуп.

Нәгыймә әби хатасын тиз үк аңлап алды да дәвам итте:

— «Тәмам» дигәнче өстәп яз: бергә уйнап үскән яшьтәшләрең Вәзирдән, Якуптан, Айдардан күп сәлам. Сәлам шуның белән тәмам.

Балам Габдулла, синең ефәктән затлы, алтыннан кыйммәтле хатыңны кичә генәк өйлә вакытында алып яшьтәшләрең Айдар, Якуп, Вәзир белән кат-кат укып чыктык. Синең асыл сөякләрең сызлаганда минем йөрәккәем әрнү бушка гына булмаган икән. Ярый, азагы хәерле бетсен инде. Бер сабый баланы һәлакәттән коткарып, күпме кешенең кайгысын җуйдың бит син. Әгәр дә ки синең күз алдыңда шул баланы үгез сөзеп үтерсә, гомер буе җаның газаптан чыкмас иде. Җан газабы тән газабыннан ачырак була ул. Инде хәзер духтырларыңны тыңлап кына тор. Савыккач телефон чыбыгы аша хәбәр ит. Колхоз рәисе Дәүләт абзаң әйтте, Габдулланы алырга иң яхшы айгырны җиктерермен, диде. Андый айгырга элек губернатор гына утырып йөри иде.

«Беләгем кычыта» дигәнсең. Әйт духтырыңа, мунча ягып кертсеннәр. Каен себеркесе белән чабып карагыз. Әмма үтә эссе чапмагыз. Күчтәнәчләреңне ашаганнан да артык булды. Эчең пошканда син үзең аша аларны. Картинәңнең күчтәнәче итеп аша. Әллә берәр дистә йомырка, берәр чүлмәк каймак җибәримме дигән идем дә, Дәүләт абзаң кире сүрелдерде. «Бәлнистә ашау җитә ул»,— диде.

Янә шул да мәгълүм булсын. Йорт-җир, мал-туар, кош-корт бары белән, шөкер, имин. Тавыклар йомырка салып тора. Теге чобар тавык унике чебеш чыгарды. Сыерның да сөте бу арада арта төште. Элекке көнне, эчебез пошып, Ямлегөл әбиең белән басуга чыккан идек. Игеннәр бик матур күренә. Түбән оч Әмирханнарның мунчасы янып китте. Башка бәла-каза күрүче юк. Иминлек алай.

Хәзер инде синең сау-сәламәт әйләнеп кайтуыңны зар-интизар булып көтеп калабыз. Кайтып күземә күренсәң, әтиеңнең медален берәр көн тагып йөрергә биреп торырмын дип торам әле. Бер көн медаль тагып йөрерлек кенә эш күрсәтмәдең түгел, күрсәттең. Гөлнур турында сорагансың. Ул сау-сәламәт, йөгереп йөри. Кош теледәй генә хатымны шушы җирдә тәмамлап, сиңа ак юллар теләп калучы картинәң.

— Ә балыклар хакында, картинәй?

— Бая да сорармын дидем дә оныттым. Нинди балыклар соң ул?

— Анысы сер, картинәй.

— Сезнең серегез бетәрме? Алайса, белгәнеңне үзең өстәп язып куй инде.

Вәзир үз белдеге белән өстәп куйды:

Габдулла, балыклар өчен кайгырма. Алар исән. Тизрәк кайт!

Хатны әйтеп торучы картинәең, язучы Вәзир.

Айдар хат язылып беткәнче үк урап кайткан иде. Басма хәрефләр белән Вәзир матур итеп адрес язды. «Тапшырырга: Габдулла Юламановка» дигән сүзләрнең астына да сызып куйды.

— Кая, картинәй, үзем йөгереп кенә почта тартмасына салып килим,— диде Якуп.

— Рәхмәт, балалар, үзем юл уңаенда салып китәрмен әле. Шул якка барасым да бар иде,— диде Нәгыймә әби. Мич артындагы тартмадан алып ул малайларга икешәр йомырка тоттырды. Тегеләр алмаска итеп карасалар да булдыра алмадылар. Сыйдан олы булырга ярамый. Бөркетледә йола бозу гаепкә санала.

— Тора биргәчрәк кереп чыксаң, Якуп, тагын бер кат укып ишеттерер идең,— дип калды Нәгыймә әби.

Якуп баш какты.

Малайлар чыгып киткәч, Нәгыймә әби, сандыктан алып, озын чуар күлмәген, яшел бәрхет камзулын киде, яңа шәлъяулыгын бәйләде. Аның башка барыр җире юк иде. Онығына хатны үз куллары белән саласы килде. Ә

шундый күңелле эшне ул бәйрәмчә киенеп эшләргә булды.

Нәгыймә әби йөгерә-атлый клуб янына килде. Әнә ишекнең сул ягында гына почта тартмасы эленеп тора. Нинди уңмаганнар бу почта кешеләре! Тартманы бер илле тузан баскан бит. Нәгыймә әби тартма өстенә кунган тузанны башта өреп төшермәкче итте. Болай гына барып чыкмагач, камзул кесәсеннән кулъяулык алып, аны әйбәтләп сөртте. Шуннан соң гына, кечкенә капкачны ачып, хатны эчкә төшерде. Ул тиз генә борылып китмәде. Тартмага шактый карап торды да йомшак картлач куллары белән аны сыйпап, сөеп куйды.

— Кош канаткайлары юлдаш булсын,— диде ул.

ЮЛ

Үз башың белән ныклап уйласаң, теләсә нинди нәрсәнең очына чыгарга була. Беркөнне кич тау ягында сыер ашатканда малайлар уйлый торгач шундый фикергә килделәр: иртәгә үк Габдулла янына барырга кирәк. Нәрсә эшләп соң әле бу уй аларга элегрәк килмәгән? «Таган»ның башлыгы газап чигеп больницада ята, ә болар, һичнәрсә булмагандай, шаярып йөриләр. Дусларының хәлен барып белү исләрендә дә юк. Шул да булдымы иптәшлек?

Малайларның өчесе дә, өйләренә кайткач, иртәгә кояш белән бергә юлга чыгачакларын әйттеләр. Габдулла исеме чыккач, ата-аналардан берәү дә каршы төшмәде. Хәтта Гөлҗимеш апа да икеләнеп-нитеп тормый риза булды. Ә Айдарның әнисе куанып ук китте.

— Әллә кайчан кирәк иде. Йөрисез шунда җыен юньсез,— диде ул. Үз балалары авызыннан өзеп булса да, Габдуллага дип әзерләгән йомыркасыннан, маеннан күчтәнәч юнәтте. Якупның әнисе кечкенә банкага салып бал, шактый гына юача куйды. Корбанбикә җиңги очырмадагы йон арасына яшергән карагат кагыннан бер олы җәймә алып бирде. «Чәенә салып эчсен, сөякне йомшарта ул»,— диде.

Башлык вазифасын вакытлыча үз өстенә алган Айдар кичтән үк иптәшләренә төрле боерыклар бирде. Кием-салымга арада иң бөтен исәпләнгән Якупка ике кат чалбар, ике кат күлмәк кияргә кушты.

— Эссе булыр бит,— дип карады тегесе.
— Эссе сөяк сындырмый ул.
Якуп төпченергә тотынды:
— Ә нигә ике кат?
— Кирәк булуы бар.
Бу юлы Вәзиргә дә сары сатин күлмәкне киярга туры килде. Әллә кая чит җиргә барып күлмәксез йөрү абруйсызлык булыр иде. Һәрнәрсәнең чамасын белергә кирәк.
Кояшның беренче нурлары офык читен тишеп чыкканда, кулларына төенчекләр тоткан өч малай юлдалар иде инде. Башта алар бик җитез атладылар, тау түбәне туры килгәндә, йөгергәләп тә алдылар. Кояш күтәрелгән саен, юлчыларның адымы сүлпәнләнә барды. Таш арасыннан чылтырап кына аккан бер чишмә янында су эчәргә туктадылар. Ләкин алар, сусаудан болай, ачыкканнар иде инде.
— Әйдәгез, тамак ялгап алабыз,— диде Вәзир. Бу урынлы тәкъдимне берәү дә кире какмады.
«Тамак ялгарга» гына утырган малайлар шушы чишмә янында көнлек азыкларын ялт иттереп кенә калдырдылар. Ашап туйгач, Айдар килештереп нәтиҗә дә чыгарып куйды:
— Ярый, көнлек азык корсакта булыр.
Чишмәдән ятып су эчтеләр дә юлчылар янә юлларында булдылар. Аларны шактый ара атлы да, машина да куып җитмәде. Малайлар, урман, тау араларын үтеп, дала юлына чыктылар. Култабан дала ягында. Вәзир юлны яхшы белә. Ул, әтисенә утырып, былтыр гына ике тапкыр Култабан базарына барган иде.
Ярты юлны үткәч, малайларны озын бүрәнә төягән тагылма арбалы машина ажгырып куып җитте. Өчесе дә кулларын күтәрделәр. Машина болар янына җай гына килеп туктады. Шофер ишекне ачып җибәрде. Ул унҗиде-унсигез яшьлек кенә егет иде:
— Кайда юл тоттыгыз, юлчылар?
— Култабанга.
— Ни җитмәгән анда сезгә?
— Безнең иптәшебез больницада ята. Үгез сөзеп имгәтте, шуның хәлен белергә барабыз.
— Утыртыгыз әле, агай.
— Йөк бик авыр,— дип шаяртты шофер,— машина тарта алса ярый да.

— Тартыр әле. Юл тигез бит,— дип тынычландырды аны Якуп.— Без җип-җиңелбез.

— Алайса утырыгыз. Тик кабинага барыгыз да сыймассыз. Берегезгә өскә кунакларга туры килер.

— Өчебез дә өстә барыйк, агай.

— Карагыз аны, очып төшмәгез. Бәлагез үзегездән зур булыр.

«Әһ» дигәнче малайлар бүрәнә өстенә менеп кунакладылар.

Дала юлы тигез, йомшак иде. Машина тирбәлдереп кенә алып бара. Малайларның күңел күтәрелеп китте. Юлның ике ягында игеннәр күкрәп үсеп утыра. Басу өстендә җиңелчә җил йөгереп уйный. Еракта, артта, таулар күгәреп ята. Бөркетле дә шул якта күмелеп калды. Таулар итәгендә төтен баганалары күренә. Җәйләүдәгеләр учак якканнар, күрәсең. Бөтен түбәләрдән югары булып, Кирәмәтнең ак түбәсе ялтырап тора. Безнең якта Кирәмәтне таулар патшасы, диләр.

Рәхәтлеккә чыдый алмый Айдар җырлап җибәрде:

Туган җиркәемә кайтыр идем,
Аяк-балтырларым талса да, имгәкләп...[1]

Җырлаганда ул бөтен дөньясын оныта. Әле дә, җырлый торгач, төенчеген ялгыш бүрәнәгә бәреп алды. Чүпрәк аша сыек нәрсә саркый башлады. Габдуллага күчтәнәчкә дигән йомыркалар шундый юка кабыклы булып чыкты. Ләкин Айдар үзе дә, башкалар да моны күрмәде. Саркып чыккан йомырка сыегы кояшта тиз үк кибеп тә өлгерде. Кара чүпрәк бөтен серне яшереп калдырды.

Култабанга җиткәч, шофер машинасын туктатты.

— Мин, авылга кереп тормый, туры китәм. Гаепләштән булмасын, егетләр, илтеп үк җиткерә алмыйм,— диде ул, ишектән башын чыгарып.— Кайсыгыздыр бик шәп җырлый икән. Юл сизелми дә калды.

— Менә бу,— дип Айдарга төртеп күрсәтте Якуп.

— Молодец, энем!

Малайлар машинадан төштеләр.

— Рәхмәт, агай! — диделәр алар өчесе дә аллы-артлы. Габдулла өлешенә кереп, Айдар шоферга ике

[1] Имгәкләп — мүкәйләп.

йомырка да бирергә уйлаган иде дә, батырчылык итмәде. «Я алмас, алмаса оят булыр»,— дип икеләнде.

— Больница авылның аргы очында, урман читендә булыр. Олы урамнан туп-туры менәсез дә китәсез,— дип юл өйрәтте дә шофер, кузгалып китте.

Юлчылар янә җәяүгә калдылар. Ләкин больница күз күреме җирдә генә иде инде. Авыл уртасындагы елгага җиткәч, малайлар өсләрендәге тузанны кактылар, юынып алдылар. Мал абзарына бармыйлар бит, больницага баралар. Һәрнәрсәнең үз рәте була.

Больница болдырында ак халатлы олы гына бер хатын сарык йонынннан шәл бәйләп утыра иде. Ихата эчендәрәк тагын бер агач йорт бар. Аның янындагы скамья артына сөялеп, яшь кенә хатын бала имезеп утыра. Койма буендагы юан карагачка аркаларын терәп, ике ир чүгәләгән. Читтән килгән авыруларны врачлар шушы йортта кабул итәләр икән.

Ихатада агачтан агачка тартылган берничә озын җепкә ак керләр эленгән. Болдырда утырган хатын, бәйләвеннән туктамый гына, ара-тирә керләргә күз салып ала. Күрәсең, шул тирәдә уралучы кәҗәләрдән саклый торгандыр. Кәҗә малы ак кер чәйнәргә әвәс була ул.

— Апа,— диде Вәзир,— без иптәшебезнең хәлен белергә килгән идек. Юламанов Габдулланы күрергә кирәк иде.

— Аның хәле шәп хәзер,— диде апа.— Дүртенче палатада ялгызы ята. Тик әле керергә ярамый. Иртәнге аштан соң йокы сәгате. Төштән соң үзе чыгар.

Дусларын күрергә атлыгып килгән малайлар өчен бу күңелле хәбәр түгел иде.

— Без шым гына керербез, апа, аяк очларына гына басып. Кертегез инде,— дип ялынды Якуп.

— Аяк очларына басып та ярамый, бармак очларына басып та ярамый. Барыгыз. Соңыннан килерсез.

— Без бик ерактан килдек бит, апа. Бөркетле авылыннан.

— Бөркетледән ни дә, Каргалыдан ни — барыбер ярамый.

Малайлар урман читенә барып зур каен күләгәсенә сузылып яттылар.

— Эшләр шәптән түгел. Көн үтә,— диде Айдар.

— Юл уңмады болай булгач,— дип өстәде Якуп.

— Юл уңмады дип уфтанып ятсак, уңмас инде. Уңдырырга кирәк аны,— диде Вәзир.

Юлчылар, пыш-пыш сөйләшеп, ниндидер киңәш корып алдылар.

Малайлар тагын больница янына әйләнеп килделәр. Болдырда шул ук хатын шул ук шәлен бәйләп утыра иде.

— Вакыт бер дә үтми бит әле, апа,— дигән булды Вәзир,— берәр эшегез юкмы шунда? Тик йөргәнче, эшли торыр идек.

— Эшлим дигән кешегә эш бетәме...

— Теләсә нәрсә кушыгыз, без өчәүләп тотынсак...

— Иренмәсәгез ни... әнә теге керләр кибеп катып бетәдер инде. Алымымны чыгыйм дип һаман кулым тими. Шуларны менә бу алачыкка ташысагыз, бер дә кулыгыз калмас. Рәхмәт алырсыз. Бер рәхмәт мең бәладән коткара ул. Тик, карагыз аны, төшереп пычрата күрмәгез!

— Без җайлап кына, апа...

Малайлар шунда ук эшкә тотындылар. Әлеге апага мөмкин кадәр ярарга тырышып, алар үтә сак, үтә ипле маташтылар.

— Була бит балалар,— дип эченнән сокланып утырды апа.— Минеке кушканны да эшләми, карыша.

Җер эленеп торган урында бераздан төенле-төенле ак җепләр генә торып калды.

— Менә рәхмәт үзегезгә. Уңган балалар икәнсез,— дип мактады апа.

— Рәхмәтне алдык инде, апа,— диде Айдар,— хәзер шул рәхмәтегез безне бәладән дә коткарсын. Безгә иптәш янына керергә кирәк.

— Ах, шаяннар, ах, хәйләкәрләр! Сезнең белән ни эшләмәк кирәк инде. Врач күреп калса, бөтенебезгә дә эләгә бит.

— Без эләгүдән курыкмыйбыз ла ул.

— Юк, юк, ярамый... Өчегезне дә кертә алмыйм.

— Сез икебезне генә кертегез. Менә бу тышта көтеп торыр.— Айдар Вәзирнең җиңеннән тартып куйды.

— Карагыз аны, тыныгыз да чыгасы булмасын.— Хатын тирә-якка күз йөртеп алды.— Дүртенче палата. Кергәч тә уң кулда икенче ишек.

Айдар белән Якуп, аяк очларына гына басып, эчкә кереп киттеләр. Вәзир болдырда утырып калды.

— Кемгә бәйлисез бу шәлне? — дип сүз кушты Вәзир. Аңа хатынның игътибарын читкә җибәрмәскә кирәк иде.

— Кияүдәге кызым сораган иде. Үзе бозау карый. Бер дә генә бушамый.

— Минем әнием тавык фермасында эшли.

— Тавыклары саламы соң?

— Тәгәрәтеп кенә торалар. Җыеп өлгереп булмый.— Монысын, әлбәттә, Вәзир арттырыбрак җибәрде.

Хатын бик сүзчән булып чыкты. Әңгәмә куерганнан-куера барды. Вәзиргә шул кирәк тә иде. Хатын үзенең бөтен белгән һөнәрләрен берәм-берәм тезеп китте. Ул шәл дә бәйли, мич тә сала, кием дә тегә, курай да тарта, пима да баса, театрда да уйный икән. Үсмер вакытында сабантуйларында малайлар рәтенә хәтта ат та чаптырган. Шундый чая кыз булган ул...

Иптәшләре килеп кергәндә, Габдулла, түшәмдәге чебеннәрне санап, караватында чалкан ята иде. Ул кинәт сискәнеп торып утырды. Исән кулы белән күзләрен уып алды. Тегеләре керделәр дә ишек төбендә катып калдылар.

— Килдегезмени? — диде Габдулла, башка сүз тапмагач.

— Килдек. Терелдеңме инде?

— Терелдем.

— Кулың да сызламыймы?

— Хәзер сызламый инде.

Малайлар беренче тапкыр бер-берсенә кул биреп күрештеләр.

— Вәзир нигә килмәде?

— Килде. Аны кертмәделәр, тышта калды.

— Менә сиңа кучтәнәч китердек. Кагы Вәзирнеке.

— Кучтәнәч өчен рәхмәт тә, тик тамакка аш бармый. Өйгә кайтасы килә. Картинәй исәнме? Балыклар тереме?

— Бөтенесе дә сикерешеп тора. Сине кайчан кайтаралар инде?

— Тагын ун көннән, диләр. Бер атнадан балчыгын куптарачаклар.

— О-һо-о!

— Чалбар булса, әллә кайчан тәрәзәдән чыгып ычкыныр идем, чалбарны гына бирмиләр,— Габдулла тәрәзә янына килде. Бу як урманга таба карый иде.

— Эт тә күрәчәк түгел,— дип өстәде ул.— Монау челтәрне ычкындырып аласың да...

— Кием-салым бездә җитәрлек ул,— диде Айдар.— Әнә Якупта ике кат.

Башкача сүз артык иде. Габдулла өстендәге ак күлмәк-ыштанны салдырып ташладылар. Аңа чалбар киярргә булыштылар. Чалбар таман булды. Тик күлмәк кенә таррак иде. Гипстагы кул җиңгә сыймады. Малайлар моңа да аптырап калмадылар. Буйлы зәңгәр күлмәкнең җиңен Якуп шытырдатып төптән үк ертты да алды.

— Кайткач, әнием тегеп куяр әле,— диде ул.

Габдулланың картинәсенә дип җыйган күчтәнәчләрен өзелгән җиңгә тутырып, ике баштан төйнәп куйдылар. Айдар тәрәзәгә элгән челтәрне сак кына ычкындырды. Сикерергә генә җыенганда, Габдулла иптәшләрен туктатты.

— Билге бирми китү ярамас,— диде ул. Тумбочка тартмасыннан каләм-кәгазь алып кечкенә генә язу язды.

«Кадерле доктор агай!

Сезгә күп рәхмәтләр яусын. Мин савыгып беттем инде. Хәзер авылга кайтып китәм. Иптәшләрем кием китергән. Балчыгын куптартырга бер атнадан үзем килеп җитәрмен.

Гаепләп калмагыз.

Габдулла Юламанов».

Тәрәзәдән башта Айдар төште. Шуннан Габдулла чыкты. Айдар аны биленнән кочаклап күтәреп үк алды. Иң соңыннан Якуп сикерде. Ул, сөрлегеп китеп, тезен карагай тамырына бәрде. Күзенә гөлт итеп ут күренде. Әмма «эһ» тә итмәде.

Урман арасына кереп, кеше күзеннән яшеренгәч кенә, Айдар, кош сайравына охшатып, сызгырып алды.

Вәзирнең зирәк колагына бу иң матур моң булып ишетелде. Шулай да ул кинәт кенә торып йөгермәде.

— Әнә теге куак артына барып кына килимче, бик кысталдым,— дигән булды.

Бу чак теге хатын аңа үзләре куйган соңгы спектакльнең эчтәлеген сөйләп утыра иде.

— Сөйләп кенә бетерим дә...

— Ул театрны безнең авылда да куйдылар. Мин карадым аны.

— Карагач, нигә башта ук әйтмәдең? Мин башкасын сөйләр идем. Алайса, менә монысын күргәнең бармы?..

Больница артында «кош» янә сайрап куйды.

— Их, ямьле дә соң шушы җәй айлары! — дип сокланды хатын.— Өздереп кошлары сайрап тора.

— Уф, эчем! — дип Вәзир бөгелеп үк төште.

— Бар, больница артына, куак арасына йөгер,— дип киңәш бирде хатын.

Вәзир, эчен тотып, урман ягына йөгерде.

АЛДА КИРӘМӘТ

Кайткан чакта малайларга машина да, ат та туры килмәде. Алар озын-озын юлны җәяү кайттылар. Ләкин ару-талуның әсәре дә юк иде.

Көн кичләүгә дүрт юлчы Кылыч аръягындагы калкулыкка килеп җитте. Кояш бу вакыт Кирәмәтнең нәкъ түбәсендә утыра иде. Моннан караганда ул ялкын бөркеп торган янар тау төсле күренә. Матур да, шомлы да. Малайлар, ерак тауга сокланып, озак карап тордылар. Айдар, үзе дә сизмәстән, кычкырып җырлап җибәрде.

Ераклардан гына ай күренә
Кирәмәткәй тауның ак ташы,
Кайларда гына булмый, ниләр күрми
Ир-егеткәй белән ат башы.

Алда Кирәмәт. Берничә көннән дүрт терәүгә таянган «Таган» аның күленә җан кертер өчен юлга чыгар. Ә юлга бер чыккан кеше максатына барып җитми кире борылмый ул. «Таган» да кире борылмас, ул биек һәм бөек тауның түбәсенә күтәрелер.

Янә еллар үтәр. Бу малайлар егет булып җитәр. Шул чакта алар Кирәмәттән дә биегрәк түбәләргә күтәрелерләр. Җирне генә түгел, күкне дә бизәрләр алар.

Сез моңа ышанасызмы? Мин ышанам.

ЭЧТӘЛЕК

Бөркетле 3
Күкрәктаудагы әңгәмә 5
Башлык сайлау 7
Вәзирнең беренче һәлакәте 15
Өйдә зарыгып көткәннәр, ахрысы 17
Өченче терәү 20
Дан түбәтәй түгел ул 24
„Үрнәк"ләр кыйрала башлады 26
Йомры-йомры йомгагым 29
„Үрнәк"ләр чылтырап кыйрала 34
Күл өстендә балык уйный 38
Иртә яңгырлы булды 41
Көймәне йөзәргә өйрәтәм 43
Яңгырдан соң 48
Вәзирнең икенче һәлакәте 54
Каптыңмы, балык карагы! 56
Үгез белән алышу 65
Хат 68
Җавап 72
Юл 75
Алда Кирәмәт 82

Мустай Карим

ТАГАНОК

(на татарском языке)

Художество редакторы Б. Әлменов

Техник редакторы С. Әхмәтҗанова

Корректорлары Ә. М. Исәнбаева, С. В. Абдуллина

Наборга бирелде 25/X-1965 ел. Басарга кул куелды 17/I-1966 ел. ПФ 07006. Типография кәгазе № 3, 84×108[1]/32. Учетн.-изд. табак 4,23. Басма табак 2,63(4,41). Заказ Л-1368. Тираж 15000. Бәясе тышлыгыннан башка 12 тиен, тышлыгы 15 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1966.

ПРОВЕРЕНО
АВГ 2016
Подпись
1

27 тиен

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1966